КӨЕНДЕРМӘСЕН ТӨЙМӘ

Дарусыз калмабызмы? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауга җавап эзләде

> 15

ЧӘҮКӘ ТАВЫ

Чишмәбашта яшәүчеләрнең тарихны саклап каласылары килә

> 16

РӘНИФ ШӘРИПОВ:

«Артык кыю язганымны үзем дә белми идем»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 120 (28893) | Җомга | 19 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131



Илдар Мөхәммәтҗанов

БӘБИГӘ ДӘ, ӘБИГӘ ДӘ

ТАТАРСТАННЫҢ КЕЧКЕНӘ САЛАЛАРЫ ИНТЕРНЕТЛЫ БУЛАЧАК

Су һәм ут кебек мөһим. Интернет һәм элемтә турында сүзебез. Баксаң, замана мөмкинлегенең бу төреннән мәхрүм җирлекләр әле дә бар икән. Интернет булу – ул бит әле блогерларны карап утыру, мобиль элемтә исә смс алмашу дигән сүз генә түгел. IT-тигезсезлекне бетерү мөмкинме?

> 6

Ишетми калмагыз

Россия Хөкүмәте автомобильне бензиннан газга күчерү чыгымын каплауга субсидия күләмен арттырган. Хәзер машина хуҗасына бу максатка тотылган акчасының 24 проценты түгел, ә 48 проценты кире кайтарылачак. Әлеге мәсьәлә «Энергетиканы үстерү» дәүләт программасы кысасында хәл ителә. Шулай итеп, транспорт өчен ягулык буларак кулланыла торган табигый газ (метан) күләмен, арттырып, 2024 ел азагына 2,7 миллиард кубометрга җиткерү күздә тотыла.
Хөкүмәттә күздә тотылганча, субсидияне арттыру әлеге ягулык төренә ихтыяҗны үстерүгә ярдәм итәчәк.

Казандагы «Кол Шәриф» мәчете, Петр-Павел соборы Россиянең күренекле урыннары рейтингына эләккән. «Яндекс» белгечләре, интернеттан файдаланучыларның нәрсә эзләүләренә карап, илебезнең төрле төбәкләрендә халык иң күп йөри торган күренекле урыннар (2 мең объект) рейтингын төзегән. Рейтингта Татарстанның иң популяр күренекле урыннары исәбенә «Кол Шәриф мәчете», Петр-Павел соборы, Казан Яшь тамашачылар театры, Мәрьям ана монастыре, Болгардагы Ак мәчет, Алабугада Шишкин музее һ.б. кергән. Ә инде төрле шәһәрләрнең Кремль корылмалары арасында, Мәскәүнекеннән соң, Казан Кремле икенче урынга чыккан. Түбән Новгород Кремле – өченче.

Ял көннәрендә Татарстанда 30 градуска кадәр эсселек көтелә. Явым-төшем юк.
Шимбә – 20 августта көндез термометрның терекөмеш баганасы +24...+29 градусны күрсәтәчәк. Төнлә суыта: +7...+9 градус. Якшәмбе – 21 августта көндез һава температурасы +25...+30 градуска җитәчәк. Төнлә дә җылы: +13 градуска кадәр.
Татарстан Гидрометеоүзәгенең башлангыч фаразына караганда, киләсе атна башында – 22–23 августта республикада явым-төшемсез эссе һава торышы саклана. Көндез +27...+32, төнлә +9...+14 градус.

Соңгы тәүлектә Татарстанда коронавирус инфекциясе йоктыручы 102 очрагы расланган. 10 июньнән башлап, иң зур сан бу, дип хәбәр итә «стопкоронавирус.рф» сайты. 63 сырхау хастаханәгә озатылган.
Пандемия башланганнан бирле республикада ковид иярттүнең барлыгы 155185 очрагы теркәлгән. 150591 кеше савыккан, шул исәптән 14е – соңгы тәүлектә.
Үлем-китем саны элеккечә үк – 1998.
Тәүлек эчендә ил буенча 35809 кешедә коронавирус ачыкланган. Роспотребнадзор исә авыру көчәйгән төбәкләрдә битлек киеп йөрүне тәкъдим иткән. Бер атна эчендә 100 мең кешегә 50 чирләүче теркәлсә, битлек режимын кертү күздә тотыла. Аны җәмәгать урыннарында, транспортта, бүлмәләрдә (эштә яки укуда) киярга кирәк булачак. Роспотребнадзорның территориаль органнарына шул хактагы хатлар җибәрелгән.

Теманың дәвамы – 3 нче биттә >

Районнарда ни хәлләр?

Зәй

19 августта районда шикәр чөгендерен ала башларга җыеналар. Район башлыгы Разиф Кәримов җитәкчелегендәге комиссия бу эшкә әзерлек белән танышты. «10 августта шикәр чөгендере заводы белгечләре татлы тамыр үсүче басуларда тикшерү үткәрде. Анда иң беренче кайсы басудан уңышны җыйнауны башлау ачыкланды. Тикшерүләр хәзерге көнгә бер гектар мәйданнан уртача уңышның 350 центнердан артыграк булуын күрсәтте. Чөгендернең шикәрлелеге – 15–17 процент чамасы. Бу уңыш җыйный башлаган чор өчен яхшы күрсәткеч исәпләнә», – диде ул. Шикәр чөгендере алуга 14 «Ропа» комбайны һәм биш төягеч әзерләнгән.
(«Зәй офыклары»)

Кукмара

Шәһәрнең Туеш микрорайонында «Һидаят» тәрбия үзәге ачылды. «Тәрбия үзәгенең беренче нигез ташына киләчәк буыннарга нәсыйхәтләр белән хат – капсула салу тантанасы узган елның 7 маенда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашында үткәрелгән иде. Бер ел дәвамында ике катлы бина сафка басты», – диде ачылышта Туеш микрорайоны мәчете имамы Айрат хәзрәт Шафигуллин. «Һидаят» үзәгендә мәктәпкәчә яшьтәге һәм I–IV сыйныф укучылары – берьюлы якынча 45 бала шөгыльләнә алачак. Мөгаллимнәр сабыйларга әдәп-әхлак дәресләрен, дин нигезләре, гарәп әлифбасын укытачак. Өстәмә рәвештә инглиз теле, мәктәпкә әзерлек дәресләре, уен зонасы ясау, мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен махсус дәресләр кертү һ.б. көтелә.
(«Татар-информ»)

Тукай

Калмия мәдәният йортында җиләк-җимешләрне җыеп, тәмле кайнатмалар, компотлар ясагач, шул кайнатмаларны алып килеп, рецептлары белән бүлешеп, кайнар коймак белән чәй эчә торган бәйрәм кичәсе – «Варенье-шоу» узды. Иң күп җиләк җыючыларны да бүләкләделәр. Беренче урында – биш литрлы 54әр чиләк җиләк җыйган апалы-сеңелле Әнисә апа Хаҗиева һәм Мәймүнә апа Гыйльфанова. Икенче урында – 40 чиләк җир җиләге җыйган Фәнисә Ямалиева. Өченче урынга чыккан Мәүсилә апа Әхмәтнурова 18 чиләк җиләк җыйган.
(«Якты юл»)

Азнакай

Шәһәрнең Зәңгәр мәчетендә хаҗилар очрашуы узды. Азнакайлыларны хаҗга әзерләү эшләре белән Гөлшат ханым Шәйхулова һәм аның улы Азат шөгыльләнәләр. Шуны искәртеп китик: ерак изге сәфәргә чыкканчы, булачак хаҗилар Зәңгәр мәчеткә укуларга йөри. Быел Азнакайдан изге сәфәргә 21 кеше чыкты. Зәңгәр мәчет имам-хатыйбы Нәфис Хәкимов быел хаҗга өченче тапкыр барып кайткан. «Быелгы хаҗ – Аллаһы Тәгаләгә бүләге. Ул җәйнең иң кызу вакытына (27 июнь – 20 июль) туры килсә дә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, сизми дә калдык, шулкадәр җиңел башкарылды», – диде ул.
(«Азнакай-информ»)

ПРЕЗИДЕНТ ӘЙТТЕ

Рөстәм Миңнеханов Биектау районында урып-җыю эшләре белән танышты, авыл җирлекләре башлыкларына яңа трактор ачкычлары тапшырды, төзекләндерелгән мәдәният йортын барып күрде.



tatarstan.ru

18 августка булган мәгълүматларга караганда Татарстан кырларыннан 2,5 миллион тоннадан артык ашлык җыеп алынган. Урып-җыю эшләре барлык мәйданның 43,9 процентында башкарылган. Гектарыннан уртача 38,5 центнер уңыш чыга. Иң күп уңыш җыйган өч район арасында Тәтеш (137646 тонна), Минзәлә (119141), Буа (116226) районнары бар.

«Бөреле» хуҗалыгы кырында Президент механизаторлар, авыл җирлекләре башлыклары, хуҗалыклар җитәкчеләре, инвесторлар белән очрашу үткәрде. Районның башкарма комитеты җитәкчесе Равил Хисаметдинов әйтүенчә, кырларда 57 комбайн эшли. Гектарыннан уртача 31 центнер уңыш чыга. Иген кырлары мәйданының 47 процентында урып-җыю эшләре төгәлләнгән инде.

Аның сүзләренә караганда, районда барлыгы 13412 баш мөгезле эре терлек асрыйлар. Узган елдагы белән чагыштырганда, терлекләрнең баш саны берникадәр кимегән. Районда шәхси ярдәмче хуҗалыкларда терлекләрнең баш саны 180гә азайган. Президент терлек азыгын әзерләүнең мөһимлегенә, аерым алганда, азык үзәкләре булдыруга игътибарын юнәлтте.

Рөстәм Миңнеханов «Татарстан муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе үткәргән республика конкурсында җиңгән авыл җирлекләре башлыкларына яңа трактор ачкычларын тапшырды. Президент шулай ук Бөреледә капиталь төзекләндерелгәннән соң ачылган Мәдәният йорты белән танышты. Төзекләндерү эшләре «Мәдәни мирас объектларын төзекләндерү» республика программасы кысасында башкарылган. Бер бинада районның балалар сәнгать мәктәбе, китапханә, балалар-яшьләр спорт мәктәбе бүлеге, дарухана урнашкан.

Моннан тыш Президент гомуми практика табибы офисында булды. Дәвалау оешмасы Татарстанда сәламәтлек саклау өлкәсенең беренчел буынын модернизацияләү программасы буенча төзелгән. Биредә 14 торак пунктка (барлыгы 4599 кешегә) хезмәт күрсәтелә. Объект заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән: физиотерапия, ЭКГ бүлмәләре һ.б. булдырылган. Сырхауларны 3 табиб кабул итә.

Биектаудан соң Рөстәм Миңнеханов Кукмара районына сәфәр кылды.

СУГА ТӨКЕРӘСЕ ТҮГЕЛ

Суның кадерен белмибез. Кечкенә елгалар саега, кибә. Сәбәбе – төзелеш, җир асты суларын суырту, грунт сулары кимү, авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать калдыкларын агызу, су төбендә куркыныч химик матдәләр туплану. Казан Кремлендә Иминлек Советы утырышында Президент Рөстәм Миңнеханов әнә шулай дип белдерде. Утырышта экология турында сөйләштеләр.

Экология мәсьәләләре инде күптән кешенең шәхси иминлегенә генә кайтып калудан туктады. Президент үзенең чыгышында басым ясап әйтүенчә, әйләнә-тирә мохитнең торышы башлыча дәүләт иминлеген билгели.

Елгаларга коммуналь, авыл хуҗалыгы, сәнәгать предприятиеләреннән пычрак сулар әләгә. Президент шулай ук сулыкларга автомобиль юлларыннан, кырлар, сәнәгать предприятиеләре территорияләреннән бик күп пычрак агып төшүен искә төшерде. «Бу мәсьәләне хәл итү юлларын табарга кирәк. Безнең бурыч – республикада яшәүчеләргә сыйфатлы, чиста мохит булдыру», – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов.

Бүген хакимияткә куела торган төп таләп – халыкның тормыш сыйфатын яхшырту. Ә табигатьне саклаудан башка гына моңа ирешеп булмый. «Моннан тыш халыкны сыйфатлы эчәр су белән тәэмин итү мөһим. Барлык авыл-бистәләрдә бакчага сибү өчен, хуҗалык кирәк-ярагы өчен су булырга тиеш. Су буенча программа эшләячәкбез. Су мәсьәләсен хәл итүгә акчаны ике тапкыр арттырсак та, бу гына җитми әле. Алдыбызда ике бурыч тора: халыкны сыйфатлы су белән тәэмин итү һәм чистарту системаларының торышын яхшырту. Хәзерге вакытта чистарту корылмаларының эше бик катгый төстә контрольдә тотылырга тиеш», – дип искәртте Татарстан Президенты.

Утырыш барышында Рөстәм Миңнеханов чистарту корылмаларының эше буенча Питрәч һәм Теләче районнары вәкилләренә сораулар бирде. Бу районнарда чистарту корылмалары төзелсә дә, әлегә алар тиешенчә эшләми.

Президент ике атна эчендә тәгаен бурычлар күрсәтелгән утырыш беркетмәсен әзерләргә кушты. Аерым алганда, «Иделне савыктыру» федераль проектын 2030 елга кадәр озайту һәм «Каманы савыктыру» федераль проектын кабул итү турында Россия Хөкүмәтенә мөрәҗәгать әзерләү күздә тотыла.

– Идел һәм Каманы савыктыру – бик кирәкле программалар, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Бу мөрәҗәгатьне, һичшиксез, әзерләячәкбез. Иделне Камадан аерып булмый дип саныйм, чөнки Иделнең яртысы Кама елгасы суыннан тора.

Рөстәм Миңнеханов шулай ук күзәтчелек органнарына хокук саклау органнары белән берлектә сулыкларны пычратучы хуҗалыкларны игътибарга алырга кирәклеген белдерде. «Гаепләнәрне җаваплылыкка тартырга кирәк, – дип катгый төстә белдерде Рөстәм Миңнеханов. – Кайбер очракларда предприятиене түгел, ә җаваплы кешеләрне штрафка тартырга кирәк, дип саныйм».

Моннан тыш Президент Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына яр буйларында төзелеш алып баручы, чистарту корылмаларын төзүче намуслы һәм намуссыз оешмалар реестрын булдырырга тәкъдим итте.

«Сулыкларны саклау өлкәсендә 2023 елгы программаны төзегәндә, иң элек эшләп килүче чистарту корылмаларын тәртипкә китерүне күздә тотарга кирәк, – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов. – Беренче чиратта, булганы эшләсен. Шәхси компанияләр чистарту корылмалары эшен тәэмин итә алмаса, аларны дәүләткә тапшырырга кирәк. Проектының дөрес булмавы сәбәпле, чистарту корылмасыннан файдаланып булмый икән, белгечләр чакыру шарт». Президент шулай ук районнар хакимиятләре башлыкларына чистарту корылмаларын төзү, реконструкцияләү һәм алардан файдалану мәсьәләләренә үзләренә үк төшенергә киңәш итте. «Бу мәсьәләне сез үзегез тирәнтен аңларга тиешсез. Катлаулы мәсьәлә. Аны хәл итүдә шәхсән катнашу кирәк», – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, федераль һәм төбәк программалары кысаларында төзелгән чистарту корылмаларының эш сыйфаты аерым игътибар таләп итә.

Президент Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына бу мәсьәләне дә контрольгә алырга кушты. «Йомшаклык күрсәтүебез аркасында, елга-күлләрне пычратуга юл куела», – дип искәртте ул һәм төзелеш министрлыгының бер урынбасарына экология объектларын төзүгә бәйле мәсьәләләр буенча эшләүне йөкләргә тәкъдим итте.

Татарстан территориясендә барлыгы 174 чистарту корылмасы урнашкан, шуларның 81е – дәүләт милкендә, 93е – шәхси кулларда. Шул ук вакытта 73 корылма пычрак суларны чистартып бетерә алмый. 2019–2022 елларда республикада 12 чистарту корылмасы төзелгән һәм реконструкцияләнгән. Финанслау федераль һәм республика бюджетларыннан тиешенчә 5,1 млрд сум һәм 2,75 млрд сум тәшкил итте.

КАЗАН КРЕМЛЕНДӘ НИ СӨЙЛИЛӘР?

Битлек, яңа парк, Салмачы бистәсе хәлләре. Татарстан Президенты матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимовадан журналистлар шул хакта сорашты.

Билгеле булганча, узган атнадагы «шимбә киңәшмәсе»ндә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов хезмәт коллективларында битлек кию режимын кире кайтарырга киңәш итте. Кайбер оешмалар, хәтта районнар бу күрсәтмәне үти башлады инде. Хөкүмәт йөртындагылар нишли?

Лилия Галимова сүзләренчә, Президент күрсәтмәсеннән соң хакимият вәкилләре битлек режимын үти башлаган.

– Әйтик, бу көннәрдә республиканың Иминлек советы утырышы булды. Барлык катнашучылар да саклану чараларыннан иде. Президент күрсәтмәсен барысы да үти. Термометрия, һаваны дезинфекцияләү чаралары да саклана, – диде ул.

Тагын бер яңалык: тиздән Казан яңа парклы булачак. Аны «Парк Хаус» сәүдә үзәге янәшәсендә балалар өчен төзергә җыеналар. Яңасы элеккеге аттракционнар паркыннан ике мәртәбә зуррак булачак, диләр.

Лилия Галимова аңлатканча, мәйданы ягыннан гына түгел, эчтәлеге ягыннан да парк зуррак һәм кызыклырак булыр дип көтелә.

– Проектны тормышка ашыру вакыты турында әлегә нидер әйтергә иртәрәк. Казан шәһәр Думасы дәрәҗәсендә фикер алышу булырга тиеш. Белгечләр үз фикерләрен җиткерергә тиеш. Экологлар, геодезия, шәһәр төзелеше буенча белгечләр җәлеп ителәчәк, – диде матбугат хезмәте җитәкчесе.

Татарстан хакимияте Салмачы бистәсе халкының зарына карата да фикерен җиткерде.

Мәгълүм булганча, анда яшәүчеләр «Газпром» һәм «Нижнекамскнефтехим» җәмгыятьләре таләпләре аркасында йортсыз калудан курка. Торак йортларны сүтү мәсьәләсе бер генә күтәрелмәде инде. Халык ачык хат белән ил Президенты Владимир Путинга кадәр барып җиткән.

Вазгыятькә ачыклык кертеп, Лилия Галимова:

– Мондый очракта без бары тик суд карары чыгарган нәтиҗәләргә генә йөз тота алабыз. Биредә төп мәсьәлә – куркынычсызлык. Хакимият вәкилләре торак йортларны сүтү буенча карарлар кабул итми. Иң мөһиме – кешеләр тормышына берни дә янамасын, – диде.

ЭКРАННАН ДА КҮРСӘТӘЛӘР

Быел «Татар сүзе» нәфис сүз бәйгесе беренче тапкыр телевизион форматта узачак. Оештыручылар – «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе һәм «Шаян ТВ» каналы. «Эстафетаны филармониядән кабул итеп алдык», – ди алар. Бәйгенең быелгы үзенчәлекләре турында матбугат очрашуында сөйләделәр.

Президент каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү комиссиясе гамәлгә куйган «Татар сүзе» халыкара нәфис сүз бәйгесе инде өченче мәртәбә уздырыла. Моңарчы оештыру эшен Татар дәүләт филармониясе башкарды. Шушы кыска гына вакыт эчендә сүз сәнгатенә, татар әдәбиятына битараф булмаучылар арасында шактый зур кызыксыну уятырга өлгерде ул бәйге. Узган ел катнашучылар саны өч меңнән артык иде. Быел да шуннан ким көтмиләр.

– Эстафетаны кабул итеп алдык. Бик җаваплы һәм мәртәбәле эш. Тагын да киңрәк аудиториягә колачлау максатыннан, быел әлеге бәйге телевизион форматта уздырылачак, – дип сөйләде «Шаян ТВ» каналы баш мөхәррире Рамилә Сәхабетдинова.

Оештыручылар гына түгел, «Татар сүзе»нең жюри составы да үзгәргән. Жюри рәисе – Татарстанның Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла. Катнашучыларны бәяләүчеләр арасында Тинчурин театры артисты Ирек Хафизов, Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, профессор Искәндәр Гыйләҗев, халык артисты Луара Шакирҗанова һәм башкалар бар.

Татарстанның Дәүләт Советы депутаты, халык артисты Рамил Төхвәтуллин әйтүенчә, бүген нәфис сүзгә ихтыяҗ кими.

– Сүз гаять зур көчкә ия. «Татар сүзе» газиз ана телебезне яклау, саклау, киләчәк буынга тапшыру миссиясен башкара. Татар телендә шигырьләр укыйлар, татарча җырлар башкаралар, гомумән, тел кулланышта бар икән, ул яшәячәк. Безнең максат та шуннан гыйбарәт, – диде ул. – Бүген нәфис сүзгә ихтыяҗ кими. Бигрәк тә эстрадада. Кешеләрнең озын-озын поэмалар тыңларга вакытлары да, теләкләре дә юк. Әмма без бирешмәскә, барыбер тырышырга тиеш. Киләчәгебез – балаларыбызның кулларында. Менә шундый бәйгеләр аша аларда да телгә, сүзгә карата игътибар уятып, талантлы балаларны барлау, тәрбияләү – безнең бурыч.

Быел да бәйгедә җиңүчеләрне саллы бүләкләр көтә. Премия фонды – 1 млн сум.

– «Татар сүзе» инде брендка әйләнде. Катнашучыларның елдан-ел артуы – моның ачык мисалы. Быел да катнашучылар күп булыр дип уйлыйбыз, инде гаризалар шактый килде, – диде оештыру комитеты җитәкчесе Роза Әдиятуллина.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Катнашучыларның эшләре түбәндәге яшь категорияләрендә бәяләнә:

- 10 яшькә кадәр (10 яшьне дә кертеп);
- 11–17 яшь (11 һәм 17 яшьне дә кертеп);
- 18 яшь һәм өлкәнрәкләр;
- үзе язган әсәрләрне сөйләүчеләр – 15 яшь һәм аннан өлкәнрәк катнашучылар;
- иҗади гаилә;
- профессионаллар.

Чыгышлар «Шигърият» һәм «Проза» номинацияләрендә бәяләнәчәк. Гаризалар 2022 елның 31 октябренә кадәр кабул ителә. Гала-концерт 2023 елның апрелендә булачак.

Айдар ШӘЙХИН

КАЙСЫН АЕРЫРГА, КАЙСЫН КУШАРГА

Матбугат битләрендә *берьюлы* дигән кушма сүзне (рәвеш сүз төркеменә карый ул) аерым ике сүз итеп язу очраклары ешайды. *Бер юлы* дигән рәвеш юк. Әгәр дә сез нинди дә булса эш-хәрәкәтнең бер үк вакытта, бер уңайдан булуын (рус телендә *разом* яки *одновременно* дип әйтер идек) аңлатырга теләсәгез, эш-хәрәкәтнең ничек башкарылуын күрсәтә торган рәвешне кулланырга бурычлысыз. Мондый рәвеш бар: *берьюлы*.

Шулай да, эш моның белән генә бетми әле. Татар теле – иллә дә хикмәтле тел шул. *Юл* сүзе телебездә күп мәгънәгә ия. Төп мәгънәсеннән тыш, ул *мәртәбә, тапкыр, кат, рәт* төшенчәләрен дә аңлата ала. Мәсәлән, мондый җөмлә булсын: *Икенче юлы аны-моны уйлап тормам, куып кына кайтарырмын*. Бәхәсле булган *бер юлы да* бу мәгънәдә кулланылганда аерым язла: *Бер юлы кайтсам, шундый тамаша күрдем!*

Истә калдырабыз: берничә эш бер вакытта эшләнсә, *берьюлы* кушылып языла; кабатлана торган вакыйганың аерым бер очрагы (юлы) булса, *бер юлы* аерым язылырга тиеш.

Укучылардан *һәрхәлдә* сүзе турында сораулар килә. Бу рәвеш тә кушылып языла. Бу – кушма сүз, ул ике сүзнең суммасы гына түгел. *Һәр* һәм *хәл, халдә* сүзләре кушылып, *бернигә дә карамый, тәгаен, төгәл* мәгънәсендәге яңа берәмлек хасил була. Аны бердәм итеп кабул итәргә кирәк, шуңа ул кушылып языла да инде.

МАТБУГАТЛАР ҺӘМ ИНТЕРНЕТЛАР

Халык матбугатларга ышанмый. Интернетлар модада. Мисал итеп китерелгән бу ике җөмләдә күплек санда *матбугат* һәм *интернет* сүзләре кулланылган. Бу мантыйклы эш түгел. *Матбугат*, ягъни пресса сүзе үзе үк күплекне белдерә. Матбугат дип басылып чыккан барлык газета-журналларны, периодик басмаларны атыйлар. *Матбугатлар* сүзе шушы җыелма күплекләрне классификацияләгән, төркемләгән очракта гына кулланыла алыр иде: *татар, рус, чуаш матбугатлары һ.б.*

*Интернетлар*ның аңлатмасы башкачарак. Күптән уртаклык исемгә әверелеп килсә дә, чынлыкта *Интернет* – ялгызлык исем, ул – «челтәрләр челтәре», бөтен дөнья буйлап үзара тоташкан компьютер челтәрләре системасының атамасы. Әйе, ул тора-бара ялгызлык исеме сыйфатларын югалта бара (*ксерокс* сүзе кебек үк), ләкин аның асыл табигате үзгәрми. Аерым челтәрләр турында сүз барса (мәсәлән, бер бинадагы санак – компьютерларны – тоташтырган локаль «интернетлар», ягъни локаль челтәрләр), бер хәл. Әмма шундый челтәрләр тупланган бердәм система күплек санда кулланыла алмый.

Хәер, үземне төзәтим. Без барыбер *матбугатлар, интернетлар, кояшлар, Меркурийлар һ.б.* дип сөйләшәбез. Шул рәвешле әйтергә теләгән фикеребез эмоциональ яктан байый төшә. Әмма татар теленең кагыйдәләрен төгәл үтәргә кирәк булган текстларда югарыда тәкъдим ителгән аңлатмага таяну зарур.

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Шәхес буласы килә

Якташым, «Казан утлары» журналы баш мөхәррире урынбасары Вакыйф Нуриев алдында уңайсыз хәлгә калдым әле.

Журналда «Бәләкәйләр» дигән рубрикада күренекле шәхесләрнең балачакларына бәйле күңелле һәм гыйбрәтле язмалар чыгып килә. Аларны геройлар үзләре яза. Шул рубрикага берәр гыйбрәт бирергә мине дә ымсындырдылар. Бәндә баласы яшәгән саен балачагына кайта, диләр. Бу дөрес тә, чөнки олыгайган саен нәкъ менә бәләкәй вакытлар күбрәк искә төшә ул. Балачак хатирәләре миндә дә бик күп булып чыкты.

Тик менә «күренекле шәхесләр» дигән сүзләргә генә бераз шикләнеп карадым: кай җирем күренекле инде минем, җә! Бу шигемне әйткәч, Вакыйф та, дустым Алмаз Хәмзин да беравыздан: «Сине бөтен татар белә икән, димәк, син – шәхес», – диделәр. Шулай итеп үземнең күренекле шәхес икәнемә ышана яздым кебек тоела башлады. Тиз-тиз генә берничә истәлек тә язып бирдем. Әммә язма янына минем бәләкәй чактагы фоторәсемем кирәк булып чыкты. Ә алар юк! Вакыйф көн саен диярлек шалтырата: «Фотосыз әллә ничек була бит инде ул, Риман абый», – ди.

Мин шаяртып карыйм: «Хәзерге көндә төшкән берәр фотоны бәләкәй итеп куеп булмыймы соң?» – дим. Вакыйф үзе көлгән була, үзе бик үпкәли.

Бөтен туганнардан сорап чыктым: «Гаилә альбомнарыгызда минем берәр балачак фотосы кысылып калмаганмы соң?» – дидем. Юк инде, чукынып китәсеңмени! Без бәләкәй чакта авылда фотограф та юк иде бугай әле. Хәтернең кайсыдыр җирендә «Пошкар Йосыф» кушаматлы фотограф шәйләнә үзе. Ул безнең авылныкы түгел иде бугай. Галифе чалбар, күн итек киеп йөрүче тәбәнәк кенә бер абзый булып истә калган. Ни өчен «Пошкар Йосыф» – шайтан белсен?! Аны безнең авылга акча түләп кенә чакырып китерәләр иде бугай. Ә бот буе бала-чага өчен кемнең акча әрәм итәсе килсен? Өлкәннәр үзләре төшкәннәр инде, ә безгә мондый хөрмәт бик тәтемәгәндер, күрәсең. Дөрес, эзли торгач, бер фото килеп чыкты. Эти белән җитәкләшеп авыл урамында төшкәнбез. Карап торышка миңа дүрт яшь тирәсе. Аякта – сандал, өстә – майка һәм шактый яңа сатин чалбар. Димәк, берәр бәйрәм уңаеннан рәсемгә төшкәнбез. Тик менә самый кирәк чагында миңа йә кемдер дәшкән, йә колхозның бердәнбер полуторкасы кычкырткан – мин артка борылып караганмын. Шулай итеп, йөзем урынында – башымның арткы ягы килеп чыккан. Ә фотограф абыйның малай-шалайга кадр әрәм итәсе килмәгәндер, күрәсең, яңадан төшергән булыр иде, диюем.

Әлеге рәсемне Вакыйфка да җибәреп карадым: «Минем башны борып булмый микән?» – дидем. Көлде генә Вакыйф. Аннан шалтыратмас булды. Ә минем, нигәдер, күренекле шәхес буласы килә иде.

Чын фотоаппаратны мин беренче тапкыр ун яшемдә тотып карадым бугай. «Юнкор» дип атала иде ул, «юный корреспондент» була инде. Әй, мәш килдек шуның белән! Бер нәрсәсен көйлисе-нитәсе юк, бердәнбер төймәсенә басасың да вәссәлам. Авылны, аның табигатен, кош-кортларны, карга-чыпчыкларны, хәтта Хупҗамал апаның «усал» дигән даны чыккан ата казын да төшердек. Газеталарга мәкаләләр, фотолар җибәрергә хыялландык. Тик менә үзебезне рәсемгә төшерү башка килмәгән. Хәер, төшергән булсак та, кемнең кем икәнен аеру бик кыен булыр иде, чөнки сурәтләр куе томан эчендә кебек килеп чыга иде.

Ә Вакыйф һаман да дәшми. Беркөнне түзмәдем, үзем шалтыраттым. Ни гаҗәп, кәефе күтәренке иде аның. Язмаларың матур гына кереп утырды, чыккач, үзең күрерсең», – диде. «Ә фото?» – димәкче идем дә, туктап калдым. Үзе бер сүз дә дәшмәде бит, димәк, чыгу юлын тапканнар. Бәлки, фото табылгандыр. Хәер, үземдә булмаганны, аларга каян килсен инде ул!

Бу көннәрдә «Казан утлары»ның чираттагы санын көтеп йөрим. Шәхес буласы килә бит, малай. Аннан соң, бүгеннән үк фоторәсемнәрне барлап куярга исәп. Еллар үткәч, бәлки, тагын рәсемемне сорарлар. Мин эре генә: «Ничәнче елда төшкәне кирәк?» – диярмен. Шәхес булу теләге олыгайган саен көчәергә мөмкин бит ул, дип әйтәсе килгән иде.

БӨЕК АФЕРАНЫҢ КАДЕРСЕЗ ЮБИЛЕЕ

Быел 14 августны тыныч кына үтеп киттек. Ә бит нәкъ утыз ел элек нәкъ шул көнне бөек бер алдауга старт бирелде: Ельцинның «Россия Федерациясендә приватизация чеклары системасын гамәлгә кертү» дигән указы белән һәр Россия гражданины (яңа туган сабыйдан алып кабер якасында торган картка кадәр) потенциаль капиталистка әйләнде.

Эш бик аздан гына тора иде: кулыңа бирелгән ун мең сумлык ваучерга дәүләт предприятиеләренең кайсының булса да өлешен – акциясен сатып аласың да дивидендлар яуганын көтеп тик ятасың. Уңышлы һәм табышлы эшли торган компаниянең калҗасын умырып ала аласың, син бәхетле: дивидендлар яңгырдан соң үрчегән гөмбәләр кебек өстеңә явып кына торачак. Рентабельсез предприятиенең акцияләрен аласың икән, үзеңә үпкәлисең инде. Бу эш белән үзең шөгыльләнәсең килмәсә, рәхим ит: дистәләгән чек инвестицион фонды, мәшәкатьне синең өстеңнән алып, син баесын өчен тирләп-пешеп приватизациядә катнашачак. Болары – ваучер инвестицион фондлары – гөмбәдән дә ныграк үрчеделәр, телевизордан реклама артыннан реклама явып, ымсындырып, җиңел байлыклар вәгъдә итте. Бу вакыйгаларны искә алганда, авторның йөрәге татлы кысыла, аны ләззәтле сагыш биләп ала. Никадәр беркатлы булганбыз без ул елларда!

Ул чакта әле Россиядә фонд базарлары юк, глобаль капитализмның атрибутлары белән без бөтенләй таныш түгел. Уңышлы предприятиеләрнең акцияләрен каян алырга икәнен дә белеп бетермибез. Иң мөһиме: 1992 елда Россиядә рентабельле эшләүче бер предприятие дә юк диярлек. Илне туләмәүләр кризисы биләп алган. Җитештерүче заводларның чимал алырга акчасы юк, алар җитештергәнне сатып алырга тиешле предприятиеләр һәм халык шулай ук бөлгенлек хәлендә. Нидер җитештереп-ясап булмый, җитештергәнне сатып булмый. Илдә сәнәгать товарлары түгел, яшәү өчен котылгысыз кирәкле азык-төлекне куллану моңарчы күрелмәгән темплар белән кимегән. Ашлычә куллану – 84, ит ашау – 80, балык һәм сөт куллану 56 процентка түбәнәйгән.

1992 елның декабрендә мин бура кадәр сыер егып суйдым, итне алучы юк иде. Тамак туклыктан түгел азык-төлекнең сатылмавы, кулларда акча юклыктан. Кинәт кенә эшләгәне өчен тиеннәр генә алып яшәүгә күчкән интеллигенция, эшсез калып, урамга куылган завод эшчеләре генә түгел, Ватанны сакларга тиешле армия ачыга иде. 1993 елның башында Владивостокта Хәрби диңгез флотына чакырылган 4 яшь моряк ачтан үлде, 250 яшь сугышчы дистрофия дигән диагноз белән (ачыгу сәбәпле ябыгу) госпитальгә эләкте. Бөтен ил шаулады. Хәрби көчләр кулында гына булырга тиешле корал кара базарда ачыктан-ачык диярлек сатыла. Яисә контрабанда ысулы белән чит илләргә озатыла. Атом-төш материалларына кадәр шулай сатылды. Иң нык саклана торган стратегик әйберләр шулай урлап сатуга чыгарылгач, гражданлык предприятиеләрендәге хәлне күз алдына китерегез инде! Урланган, таланган, йолкынган һәм бөлгән җитештерү мәйданнары сатуга куелырга һәм, аларны сатып алып, ач россиялеләр арасыннан тиз арада урта сыйныф калкып чыгарга һәм икътисадны алга этәрергә тиеш дип саналды. Һәрхәлдә, ваучерлы приватизациянең идеологик асылын безгә шулай аңлаттылар.

Номиналь бәясе ун мең сум дип саналган ваучерның чын бәясе, имештер, ике «Волга» автомобиленә тора. Ваучерның «әтисе», ул чордагы федераль хөкүмәтнең вице-премьеры Чубайс әфәнде приватизация чегын шулай бәяләде. Совет чорының затлы автомобиле булып саналган «Волга» – иң кыйммәт йөрүче машина, аның бәясенә 3–4 «Жигули» алырга була иде. Мин үзем ул машинага бары тик бер тапкыр утырып карадым. 1992 елныңмы, 1993 елныңмы маенда профессор Фәрит Миргалимович Хатиповның 1960 нчы елларда чыккан иске машинасын ремонттан соң сынап карап, Казан тирәли әйләндек. Соңыннан ул искене сатып, Фәрит абый яңа «Жигули» алды. Кулга ваучер тотканда, без менә шундый ике байлыкка тиенгәнебезгә ышанып, дулкынланып алырга тиеш идек.

Алай була алмавын, ил байлыгын кулларга тигезләп бүлү мөмкин түгелен чамалый идек, әлбәттә. Чубайс әйткән бәягә берәү дә ышанмады. Кулдагы чыпчык һавадагы торнага караганда яхшырак, дип санаучылар ваучерларны саттылар. 1993 елның маенда бер приватизация чегы бәясе 3–4 мең сум йөри иде. Чагыштырыгыз: 1993 елда ипи бәясе 200дән алып 500 сумга кадәр тора иде. Бу – социаль әһәмиятле продукт буларак йөгәнләбрәк торган бәя.

Пассив күпчелек ваучерларын чек инвестиция фондларына тапшырды. Рәсми даирәләр тарафыннан хупланган фондлар бар иде. Татарстан укытучылары өчен махсус «Образование» дигән фонд оешты. 1993–1994 елларда Россия матбугатында Татарстан фондларының активлыгы турында язмалар күренде. Рус патриотлары татарларның иң өметле предприятиеләрне үз кулларына төшерүләреннән зарланыштыргаладылар. Яңа мәйданга чыккан фондлар беренче елда бик мул һәм ымсындыра торган дивидендлар түләделәр. Аларның акционерлары ул чакта оештыручылар үзләре генә икәнлеген әйтеп тормадылар, билгеле. Без әле кулга ваучерларны алып та өлгермәгән идек, кемнәрдер инде аларның өлешчесенә әйләнергә өлгереп баеп та яталар дигән иллюзия тудырылды. Укытучыларның күпчелеге тыныч кына, «акмаса да тамар» дигән уй белән, ваучерларын «Образование»гә тапшырды. Гаилә әгъзаларының ике «Волга»сы да күп очракта шул юлдан китте. Чеклар җыеп алынгач, фонд дивидендлар түләүне бик нык киметте, тиеннәргә генә калдырды. Дивидендлар алу өчен кайбер мәгълүматлар соралган хатлар килгәләде дип истә калган. Вәләкин табыш шундый иде: җавап хаты язсаң, конверт бәясен капларга да җитми. Фондны оештырган шәхес төшеп калмады калуын. Россия байларының исемлегендә үзенә лаеклы урын тапты. Соңгы елларда Франциядә затлы замок сатып алып, Европада тамыр җәйде. «Образование» исә бөлде ул, миллионлаган сумлык зыянга эшли башлады. Хәер, ул вакытта инде аның беренче оештыручысының фондка бернинди дә катнашы юк иде. Без исә, миллионлаган Россия гражданнары, алтыннарны җиргә күмеп, үсеп чыгуын көтеп утырган Буратинолар хәлендә калдык.

Ваучерга акция сатып алып отучылар булды булуын. «Газпром» акцияләре кыйммәтләнеп, ваучерны шуларга алыштыручылар арасында, чынлап та, машина алучылар булгалады. Вәләкин «Газпром» да ваучерлата төрле төбәктә төрлечә бәяләнә иде. Түбән Новгород өлкәсендә 1994 елда бер ваучерга РАО «Газпром»ның 2000 акциясен биргәннәр. 2008 елда боларны 700 мең сумга сатарга мөмкин булган. Ярыйсы гына ике машина алу мөмкинлеге биргән Чубайс кәгазе. Мәскәү өлкәсендә исә приватизация чегын «Газпром»ның 700 акциясенә генә алыштырганнар. Бу – 2008 елда 245 мең сумга тиң байлык. Шулай ук ярыйсы, яңа машина алырлык. Мәскәүнең үзендә ваучер табигый монополиянең 50 акциясен генә гарантияләгән. Монысы «Газпром»ның иң кыйммәт чагында 17 мең сум гына табыш биргән. Ваучерга алыштырганнан соң күзгә күренерлек табыш биргән башка компанияләрнең акцияләрен атау кыен. Нефтьчеләр бар инде. Әммә нефть компанияләрен сатканда, анда эшләүчеләр, бигрәк тә топ-менеджерлар өстенлекләрдән файдалана иде. Шуңа күрә номиналы бертөсле булса да, старт вакытында ук приватизация чегы төрле катлау кешеләренә төрле мөмкинлекләр ачты. Ул чактагы дәүләт предприятиеләренең җитәкчеләре ваучерлаштырудан оттылар, әлбәттә. (Сүз матди яктан оту турында бара, тормыштагы отышны-уңышны бу юллар авторы, мәсәлән, бөтенләй башкача бәяли.) «Кызыл директор»ларның байтагы «Форбс»ның миллиардерлар исемлегенә эләкте. Үзләре эләкмәсә, балаларын этеп кертте.

Россия приватизациясе «гасыр аферасы», «гасыр мошенниклыгы» буларак тарихка язылды. Бу язманың авторы, ул эпопеяны искә төшергәндә, «оттырдым» дигән һичбер үкенеч кичерми. Ерак яшьлекнең бер истәлеге итеп кенә карый үткәндәге хәлләргә. Шуңа күрә беркемне дә ләгънәтләми дә, йөрәгендә үч ташы да йөртми. Фамилиянең миллиардерлар исемлегендә булуы бәхет гарантияләми, шуны белә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

«СМП БАНК»НЫҢ КАЗАНДАГЫ ФИЛИАЛЫ ИДАРӘЧЕСЕ РАМИЛ КАШАПОВ:

«БЕЗНЕҢ ЭШТӘ ИҢ МӨҺИМЕ – КЛИЕНТЛАР»

Буа районының Кайбыч авылында 800 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән товарлыклы сөтчелек комплексы ачылды. «Ак Барс» холдинг компаниясе акционерлык җәмгыятенә караган «Авангард» ҖЧҖ проекты бу. Районда җитештерелгән сыйфатлы сөт күләмен арттырырга ярдәм итәчәк әлеге комплекс төзелеше чыгымнарын «СМП Банк» акционерлык җәмгыятенең Татарстандагы филиалы каплаган. Ни өчен оешма нәкъ менә шушы ферма төзелешенә алынырга булган? Рамил КАШАПОВ белән шул хакта сөйләштек.

:: «Ак Барс» холдинг компаниясе белән хезмәттәшлек кайчан башланды?

– 2020 елда Татарстанда «Кумәч-кондитер комбинаты» акционерлык җәмгыятенең җитештерү егәрлекләрен яңарту һәм төзекләндерү буенча зур масштаблы проект тормышка ашырыла башлады. Дәүләт программасы кысасында «СМП Банк» тарафыннан бирелгән ташламалы инвестиция кредиты «Ак Барс» холдингына Татарстанның икмәк пешерүче оешмалары арасында лидерга әверелергә ярдәм итте.

:: Ни өчен сез нәкъ менә товарлыклы сөтчелек фермасы төзелеше проектын сайладыгыз?

– Безнең өчен хезмәттәшлекнең бизнес ягы гына әһәмиятле түгел. Без төбәк үсеше өчен мөһим булган тәкъдимнәрне дә бик теләп күтәреп алабыз. Бүген ачылган ферма – заманча һәм югары технологияле оешма булудан бигрәк, төбәк үсешенә тагын бер зур адым да. Аның «СМП Банк»ның финанс ярдәме белән тормышка ашырылуы белән горурланам.

:: «СМП Банк» бүген аягында нык басып тора, димәк?

– Безнең эштә иң мөһиме – клиентлар. Кешеләргә һәм бизнеска үзләренең планнарын, хыялларын чынга ашырырга ярдәм итү – безнең төп максатыбыз. «СМП Банк» – Россия базарындагы тәҗрибәле уенчы. Тупланган тәҗрибәне клиентларыбыз үзләрен ышанычлы хис итсен, киләчәккә өмет белән карасын өчен кулланабыз.

Фикер

Иван ЕГОРОВ, «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры:

– «СМП Банк» – динамик, хәрәкәтчән, карарларны тиз арада кабул итүче банк. Ул катлаулы тармакларга керергә курыкмый. Яшерен-батырын түгел, авыл хуҗалыгы әнә шундый өлкә санала. Монда күп нәрсә һава торышына, мал-туарның саулыгына бәйле. Монда билгеле бер хәвеф-хәтәр дә бар. Шуңа барлык банклар да бу тармакта эш алып барырга атлыгып тормый. «СМП Банк» исә ике ел эчендә ике зур инвестиция проектын эшләтеп җибәрде. Алар икесе дә авыл хуҗалыгы тармагына карый. Шуңа күрә бу банк белән эшләвебезгә шатбыз.

Уңышларыбыз игътибарсыз калмагач, бик рәхәт. «СМП Банк» быел «Кече-урта эшмәкәрлек өчен иң яхшы программа» бәйгесендә «Дәүләт сатып алулары өчен иң ышанычлы партнер» дип исемләнгән номинациядә җиңү яулады, безнең «SUPREME» МИР картасы исә маркетинг һәм лояльлек өлкәсендәге «CRM LoyaltyAwardsRussia 2022» милли премиясендә «Елның иң яхшы картасы» номинациясендә иң яхшысы дип табылды. Моннан тыш Халыкара кредит рейтингы (НКР) һәм «Эксперт РА» рейтинг агентлыклары тарафыннан даими фараз белән «СМП Банк»ның ruA дәрәҗәсендә кредитка сәләтлелек рейтингы да расланды.

:: «СМП Банк»ның Татарстандагы өстенлекле максат-бурычлары турында да сөйләп китегезче.

– «СМП Банк» республика халкына – физик затларга да, юридик затларга да – бик күп продукт һәм хезмәтләр тәкъдим итә. Корпоратив бизнес белән эшләү, кече һәм урта эшмәкәрлек тармагы оешмаларын кредитлаштыру – өстенлекле юнәлешләребезнең берсе. Моннан тыш без ипотека программаларын да тормышка ашырабыз. Быелгы җәйдә «СМП Банк»ның Татарстан филиалы белән «Ак Таш – Инвестстрой» махсуслашкан төзүче оешма яңа төзелүче йортларда торак сатып алу өчен субсидияле ипотека бирү программасы буенча хезмәттәшлек итә башлады. Шул рәвешле хәзер республика халкына еллык ставкасы 0,1% булган ипотека алу мөмкинлеге тудырылды.

:: Банкның бизнес белән эшләгәндәге көчле якларын ничек тасвирлар идегез?

– Безнең өчен һәрбер клиент үзенчәлекле, без һәркемгә шәхси мөнәсәбәт күрсәтәбез. «СМП Банк»та кече һәм урта эшмәкәрлек өчен даими рәвештә яңа продуктлар пәйда булып тора. Алар эшмәкәрләргә үз алдына куйган бурычларын хәл итеп, үз бизнесларын һәм ил икътисадын үстерергә ярдәм итә.

:: Татарстандагы «СМП БАНК»ның киләчәккә планнары нинди?

– Эш күп, планнар зурдан. Иң беренче чиратта без үзебезнең клиентлар базасын актив рәвештә үстерүебезне дәвам итәргә, элеккеге кебек үк, республика башкаласы белән генә чикләнмичә, Татарстанда эшләү географиясен киңәйтеп, төбәк икътисадына инвестицияләрне арттырырга җыенабыз.

:: Сезнең банк тарафыннан тәкъдим ителгән MIR Supreme премиаль карталарының асылы турында да сөйләп китегезче. Аларны кайларда кулланып була?

– MIR Supreme премиаль карталарын иң беренчеләрдән булып чыгара башлаган банк без. Аңа ия булган кешеләр аэропорт һәм тимер юл вокзалларындагы бизнес-залларга үтеп керә ала. Әлеге карталардагы акчаны теләсә кайсы банкоматта бушлай алып була. Моннан тыш MIR Supreme картасына ия булучыларга ресторан, такси һәм супермаркетларда түләгән акчаның – 5 проценты, теләсә кайсы башка түләүләрнең 1,5 проценты күләмендә акча, икенче төрле әйтсәк, кешбэк кире кайта.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СМП БАНК
Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 19/8 нче йорт
8-800-555-2-555 (Россия буенча шалтырату бушлай),
+7 (843) 514-90-76, +7(843) 514-90-75
Реклама 16+

Нихәлләрдә ятасыз?

Ландыш НИГЪМӘТҖАНОВА, Татарстанның атказанган артисты:

– Эшләмәгән эш калмады бу җәйдә. Тавыклар үстереп, аларны суеп урнаштырдык инде. Яшелчәләрне дә эшкәртәбез. Бакча җимешләре дә бик күп. Җәй буе эшләп кенә ятмадык, туйлар, юбилейлар, туган көннәрдә чыгыш ясадык. Быел концертлар да күп булды. Сабан туе да җәй буена сузылды. Кыскасы, иҗаттан аерылмадык. Мин озаклап ял итәргә яратмыйм. Шуңа да җиң сызганып, яңа җырлар, яңа чыгышларга әзерләнәм. Хәзер инде балаларны мәктәпкә әзерлибез. Гаиләдә өч укучы бар.

Ирек МАНСУРОВ, завод эшчесе (Чаллы):

– Ике көн эшлим, ике көн ял итәм. Минзәлә районыннан бер бакча алган идек. Бәясе арзан булгач, кызыктым. Хәзер андый акчага бакча түгел, бер урындык та алып булмый. Кызык ясап, бакчалы булдым. Без бит – авыл балалары, җир үзенә тартты. Күп итмичә генә кыяр, помидор, кишер, чөгендер, суган утырттык. Ике көнгә бер зур чиләк помидор, ике чиләк кыяр җыеп алам. Тик менә соңгы баруымда күңел төште әле. Бакчага сукыр тычкан иярләшкән. Чөгендерне дә ашаган, инде кишергә күчкән. Көзне көтмичә, кишерләрне җыеп алып кайттык. Быелгы җәйгә рәхмәт инде. Бакчаларда җиләк-җимеш күп. Кая куярга да белгән юк.

Гөлсирә ГАРИПОВА, укытучы (Казан):

– Мин быел беренче тапкыр мәктәпкә укытучы буларак килеп керәчәкмен. Бик тә шатлыклы хисләр белән яшим. Кечкенә вакыттан ук балалар укытасым килде. Кайсы мәктәпкә барасымны хәл иттем инде. Беренче сыйныфка килүчеләрне укытачакмын. Инде әти-әниләре белән хәбәрләшеп торабыз. Сыйныфны тәртипкә китердек, яңа уку елына әзербез. Быел рәхәтләнеп ял да итә алдым. Әти-әнием белән Кырымга барып кайттык. 20 көнгә якын диңгез буенда яшәдек. Бар теләгем: укучылар һәм аларның әти-әниләре мине яратып кабул итсен иде. Ә мин, укытучы буларак, сабыйларга белем бирер өчен көчемне кызганмаячакмын.

Василий ИВАНОВ, тракторчы блогер (Кукмара):

– Комбайнда сенаж әзерлим. Бу арада күп эшләп ташладым. Бүген ял бирделәр әле. Көнемне бушка уздырмадым, ашлык алдык. Быел эшебез матур узды. Колхоз хатыным белән миңа шифаханәгә юллама бирде. Бик аз суммасын гына үзебез түләдек. Хезмәт хакыннан тотылып калгач, гел бушлай төсле булды ул. Балаларны да онытмадык. Аларның да сәламәтлеген ныгыттык. Мәктәп кирәк-яракларын әллә кайчан алып куйдык инде. Хатыным белән әнинең – үз «урак өсте». Бакчада нәрсә үсә, шуннан әллә ниләр ясыйлар.

Роза ХӘЛИЛОВА, фельдшер (Арча районының Сарай-Чокырча авылы):

– Өч авылга хезмәт күрсәтәм. Берсенә – 5, икенчесенә 11 чакрым йөреп эшлисе. Һәр авылда мине көтеп торалар. Авыру җәенә дә, кышына да карамый. Гел нидер булып тора. Җәен күбрәк төзелеш вакытында имгәнәләр. Аякларына кадак кергән кешеләр күп. Андыйларга шунда ук инфекциягә каршы вакцина ясыйм. Кайчак минем ярдәм дә җитеп тора. Авыруның хәле авыр икән, беренче ярдәм күрсәтәм дә тизрәк «ашыгыч ярдәм» чакырам. Өлкәннәр кан басымы уйнап тилмерә. Көннәрем өч авыл арасында уза. Өйгә кайтып, зурлап, ниндидер эшкә тотынырга куркам. Чакырып алучылар күп. Өйдә башлаган эшне ташлап чыгып китәргә туры килә. Фельдшерның ялы юк инде аның. Әле отпускымны алмаган. Ялга чыксам да, әллә ни ерак китеп булмый.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

БӘБИГӘ ДӘ, ӘБИГӘ ДӘ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Илдар Мөхәммәтҗанов

Аралашу урыны гына түгел

Авыл кешесенә күрше сыерының кайда адашып йөргәнен, кайчан суны туктатып торуларын, кич утыру, балны ничә сумнан сатуларын белер өчен дә интернет кирәк хәзер. Тәгәрәргә, телефон һәм социаль челтәрләр, шунысына кушылу өчен югары тизлекле интернет кирәк. Салада яшәүчеләрдән интернетның әнә шундый файдалы яклары турында сораштырдык. Шунысы да бар: вакыт дигәнне дә, эш дигәнне дә онытытыра торган зыянлы ягы да юк түгел шул замана мөмкинлегенең.

Татар блогеры Ринат Галиәхмәтов интернетлы тормышның уңай һәм тискәре якларын барлады, үзенең дә гаджетсыз вакытларын искә төшерде.

– Район үзәкләре – Мамадыш та, Кукмара да безнең авылдан шактый ерак иде. Авылыбыз тау астында урнашкан, бездә элемтә беркайчан да булмады. Авылыбыз да әллә ни зур түгел. «Билайн» операторы тота иде, анысының да элемтәсен агач башына менеп диярлек эләктерә идек. Интернетсыз, телефонсыз бик бәхетле яшәгән без! – дип сөйләде ул. – Хәзер авылда интернет бар. Әмма аның өчен кыйбат түлиләр шул. Сыйфаты да бик үк яхшы димәс идем.

Авыл кешесе өчен интернет, элемтә төшенчәләре хәзер нинди әһәмияткә ия соң?

– Интернет, телефон булгач, туганнарым мине күзәтә башлады. Шул рәвешле булса да араларны якынайтырга мөмкинлек бу. Интернетка нәрсә генә куйсаң да: «Әһә, Фаил абый белән Руфинә апа мине карады!» – дип уйлап куям. Үзләре дә берәр нәрсә урнаштырсалар, сөенәм. Яңалыклар белән танышалар. Очрашкач, барысы турында да фикерләшәбез. Интернет булу файдалы. Бу фикер киңлеге өчен дә кирәк, кызыксыну даирәсе дә арта, телефон белән эшләргә өйрәнәләр. Телевизор, радио башка нәрсә инде ул. Интернет – кызыксыну өчен зур этәргеч, – ди блогер.

Авыл кешесенә интернет үз эшен, сорауларын хәл итәр өчен дә кирәк әле. Ринат моңа бәйле бер мисал да китерде.

– Авыл чатлары бар бит хәзер. Әмма мин аларга кушылырга яратмыйм. Тик файдалы яклары да бар аларның. Миңа берсендә чеби сату тәкъдиме белән чыктылар. Бартер шартларына килештек. Чеби сатучы апа: «Тирә-күршеләрдән дә сора әле, чеби кирәк кеше юкмы икән?» – дип сорады. Чатка бер язуыбыз җитте, бер машина чебине сатып та җибәрде, – дип сөйләде блогер.

Арчаның Наласа авылыннан Рамил Мөхетдинов та, сала кешесе өчен телефон һәм интернет – тормыш-көнкүрешне җиңеләйтүнең бер чарасы, дигән фикердә. 238ләп хуҗалыклы, 700дән артык кеше яшәгән авылда бигрәк тә.

– Интернетсыз авыллар сирәктер инде ул. Дөньяны интернеттан танып беләбез бит хәзер. Авылыбызда интернет яхшы эшли. Авылдашлар телефон аша аралаша. «Ватсап»та төркемебез бар. Бик актив без анда! Бик уңайлы мәйданчык бит ул. Онлайн җыелыш ясап алырга да була. Һәркем фикерен калдыра. Йөзгә карап әйтергә оялганны да язып салырга мөмкиннәр. Социаль челтәрдә авыл яңалыклары белән уртаклашабыз. Читтә яшәүче авылдашлар өчен уңай чара. Андагы мәгълүматны күреп, куанып язалар. Дөньяда төрле хәлләр була бит. Мәсәлән, авылыбызда янгын чыгып, авылдашларыбыз йорт-җирсез калды. Аңа нәкъ тә интернет ярдәме белән булыша алдык. Шөкер, хәзер яңа йорт җиткерәләр. Мондый очракларда да ярдәме бар виртуаль дөньяның! – дип сөйләде ул. – Хәләл җефетләребез өчен дә кирәк интернет. Тормыш иптәшем яңа төрле рецептлар эзләп, интернетка еш мөрәҗәгать итә. Ул кыяр, помидор тозлау, салат ясау, компот ябуның яңадан-яңа ысулларын сынап карый. Кыскасы, файдалана белсәң, интернет – шәп ярдәмче. Тискәре ягы да бар инде. Вакытны урлый! Шунда кирәкмәгән мәгълүмат карап, биш минут утырам дип, бер сәгать үткәне сизелми дә.

Цифрлаштыру елы буләге

Әмма интернет һәм элемтә тотмаган урыннар калмады, дияргә иртәрәк. Саннарга күз салсаң, Татарстанда шундый 624 торак пункт бар икән. Бу – республиканың барлык торак пунктларының 20,25 проценты дигән сүз. Ел башында тармак өчен җаваплы җитәкчеләр дә, югары тизлекле интернет юклыгы Татарстан халкының 3 процентына кагыла, дип әйткән иде. Быел кәрәзле элемтә инфраструктурасын үстерүгә җәлеп ителгән акча күләме дә, алдагы ел белән чагыштырганда, азрак булуын таныдылар. Сәбәпләре мәгълүм: геосәяси вакыйгалар, санкцияләр һәм логистика эшенең бозылуы.

Шулай да могҗиза көтеп утырып кына булмый. Татарстанда Россиянең аз санлы торак пунктларын мобиль интернет белән тәэмин итү буенча федераль программаны гамәлгә ашыра башлаячаклар. 2G һәм 4Glы станцияләр республиканың 26 авыл җирлегендә урнаштырылачак. Интернетлы-элемтәле булу бәхете Саба, Арча, Кама Тамагы, Мамадыш, Азнакай, Баулы, Балык Бистәсе, Актаныш, Кукмара, Алексеевск, Биектау, Алабуга, Яшел Үзән, Апас, Тукай һәм Яңа Чишмә районнарының салаларына елмаячак. Аерым алганда, сүз Алан, Ташлы, Аккүл Бигәнәй, Шестая Речка, Каенсар, Яңа Мусабай, Ивановское, Шәдче, Балтач, Сарлы, Яңа Мичән, Сабабаш, Удмурт Ташлысы, Татар Ямалы, Шама, Коры Көрнәле, Чарлы, Иске Салман, Иске Тахтала, Гәр, Түбән Биябаш, Мальцово, Горшково, Яңасала, Югары Ушма, Штерә авыллары турында бара.

– Хәзерге көндә югары тизлекле интернет ул – ут, су, газ кебек үк кирәкле чара, – ди Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин. – Шуңа күрә шәһәр һәм авыл арасындагы мондый тигезсезлекне бетерүне министрлык үз эшенең өстенлекле бурычларыннан берсе дип саный. Шушы федераль программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә авыл халкы беренче тапкыр югары тизлекле мобиль интернетка тоташу мөмкинлеген алачак. 2030 елга республиканың 624 авыл җирлегендә югары тизлекле интернет барлыкка киләчәк.

Элемтә челтәрләре белән тәэмин итү «Ростелеком» җилкәсенә төшәчәк. Программа 2030 елга кадәр исәпләнгән. Ул «Санлы икътисад» илкүләм программасының «Мәгълүмати инфраструктура» федераль проекты кысасында тормышка ашырыла. Гомумән алганда, Россия буенча «Цифрлы икътисад» илкүләм программасы кысасында ел ахырына кадәр кеше саны аз булган 2 меңнән артык торак пунктны интернетлы итәргә җыеналар. 2021 елда 4G элемтәсе 1,2 мең торак пунктта барлыкка килгән иде.

– Кеше саны аз булган торак пунктларда мобиль элемтә һәм интернет пәйда булу – авылдагы тормыш дәрәҗәсен арттыруга мөһим адым ул. Тиздән авыл халкы дистанцион рәвештә укый, телемедицина мөмкинлегеннән файдалана, социаль челтәрләрдә туганнары, якыннары белән аралаша алачак. Без бу социаль әһәмиятле проектта катнашуыбызга шатбыз һәм авыл халкы өчен көтеп алынган вакыйганы тагын да якынайтабыз, – дигән фикердә «Ростелеком»ның Татарстандагы бүлеге директоры Павел Гонцов.

База станцияләрен җепселле-оптик элемтә линияләре белән тоташтыру планлаштырыла. Бу – мәгълүмат тапшыру югары тизлектә булачак дигән сүз.

Министрлык мәгълүматларына караганда, исемлеккә кергән торак пунктларның 26сында да әзерлек эшләре башланган икән инде. Саба районындагы Мичән авылы башлыгы Айзат Гәрәев тә бу сүзләрне раслады. Санлы мәгълүматларга ышансаң, салада 500дән артык кеше яши. Интернет бер дә булмаган түгел аларда, әмма начар тоткан.

– Авылның бер башында элемтә яхшы булса, икенче очына кадәр көче җитми иде. Хәзер менә «Ростелеком» операторына кушылачакбыз. База станциясенең кайда урнашуы билгеле, урыны тәгаенләнде. Чыбыкларын да әзерләп куйдылар. Тиздән эшчеләре дә күренер инде. Халык ризасызлык белдермәде, – диде ул.

2022 ЕЛ

WE ARE SOCIAL АГЕНТЛЫГЫ ҺӘМ KEPIOS ХЕЗМӘТЕ РОССИЯНЕҢ ЦИФРЛЫ ТАРМАГЫНА БӘЙЛЕ СТАТИСТИК МӘГЪЛҮМАТ БЕЛӘН УРТАКЛАШТЫ

129,8 млн кулланучы

Гомуми халыкның **89%**

Интернет кулланучылар саны 1 елда **5,8 млн** кешегә арткан

Интернетта утыруның уртача вакыты – **7 сәг 50 мин**

26 августта сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Лилия ГЫЙМАЗОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Өстәмә акча тиешме?

Мин – Казанда яшәүче 79 яшьлек ялгыз карчык. Ирем күптән вафат, балаларым юк. Минем 41,5 еллык хезмәт стажым бар. Бүген картлык буенча 22 мең 793 сум пенсия алам. Ялгыз пенсионерларга пенсиягә өстәмә түләү каралган дип ишеткән идем. Бу – дөрес сүзме? Минем кебек ялгыз пенсионерларга нинди ташламалар каралган, аңлатып китмәссезме?

Наилә ВӘЛИЕВА. Казан

Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге:
– Кызганыч, 80 яше тулмаган ялгыз пенсионерларга берниндн өстәмә түләүләр дә каралмаган. 80 яшегез тулгач, сез өлкән кешене тәрбияләгән өчен каралган 1200 сум компенсацияне рәсмиләштерә аласыз. Закон нигезендә, аны рәсми рәвештә эшләмәүче башка кеше рәсмиләштерергә тиеш. Ул кешенең сезнең туганыгыз булу-булмавы, бергә яшәү-яшәмәвегез дә мөһим түгел.

Вакыты нигә үзгәрде?

Пенсиямне «Сбербанк» картасына алам. Моңарчы аны һәр айның 12 нче числосында ала идем. Бер ай элек пенсия алу вакытын 16 нчы числога күчерделәр. Анысын да төштән соң гына алып була. Бик уңайсыз. Пенсия алу вакытын ник үзгәрттеләр икән?

Актаныш районыннан Мөхәммәтготыф абыегыз

Саклык банкының «кайнар элемтә»се:
– 24 июньнән пенсиясен Саклык банкы картасына алучы пенсионерларга кагыйдәшлы үзгәреш гамәлгә керде. Аның нигезендә хәзер пенсияне шушы юл белән алучы өлкәннәргә пенсия төштән соң күчереләчәк.

Кире кайтарып буламы?

Бер көнне түләүле клиникага барып, теш яматкан идем. Өч көн дигәндә пломба килеп тә төште. Клиникага шалтыратып, хәлне аңлаткач, моның өчен түләгән акчаны кире кайтарудан баш тарттылар. Үзләре гаепле булгач, сыйфатсыз эш өчен алар акчаны да кире кайтарырга тиештер бит инде?

Фәрит ХӘНӘФИЕВ. Әлмәт

Юрист Илнур Гарифуллин:
– Закон буенча, табиб бер ай элек үзе куеп җибәргән пломбаны да, төшкән очракта, бушлай яңадан куярга тиеш. Белгеч күрсәткән хезмәттән канәгать булмавыгызны эш барышында яки процедурадан соң ук белдерсәгез яхшы. Кимчелекләрне күрә торып, моның белән килешкән булсагыз, алга таба сезгә бу хезмәтне күрсәткән оешмадан нәрсә дә булса өмет итүдән мәгънә булмаячак. Сезнең очракта хезмәтнең сыйфатсыз күрсәтелгәнлеге соңрак ачыкланган. Шуңа күрә монда килешү төзегәндә язылган шартларга таянырга туры киләчәк. Закон буенча, хезмәтнең сыйфатсыз күрсәтелгәнлеге соңрак ачыкланса, кеше килешүдә күрсәтелгән гарантия вакыты дәвамында акчасын кире кайтаруларын яки хезмәтне яңадан, бушлай күрсәтүләрен таләп итә ала. Килешүдә гарантия вакыты күрсәтелмәгән булса, шушы хезмәт күрсәтелгән көннән башлап, ике ел эчендә шундый дәгъва белдерергә мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Рефинанслау отышлымы?

Ипотека кредитын рефинансларга җыенабыз. Болай эшләсәң, торак сатып алганда тотылган акчаның 13 процентын кире кайтарып булмаячак икән, дип ишеттем. Бу чынлап та шулаймы? Гомумән, ипотека кредитын рефинанслау отышлымы ул?

Алсу ХӘЛФИНА. Арча

Риэлтор Дамир Сафиуллин:
– Рефинанслау ул – булган кредитны каплау өчен түбән ставкалы яңа кредит алу дигән сүз. Икенче төрле әйткәндә, кредитны яңа шартлар белән башка кредитка алмаштыру. Аның ярдәмендә кеше айлык түләүне, йә булмаса, кредитны түләү вакытын кимętә ала. Шул рәвешле шактый акча янга кала. Әмма рефинанслау ясаганда кеше ким дигәндә 100 мең сум акчаны янга калдырырга тиеш. Шулай булмаса, бер кредитны икенчесенә алмаштырудан мәгънә юк. Кредит түләү вакыты 5 елдан да азрак калып барган кешегә дә кредитны рефинанслаудан файда юк. Билгеле булганча, торак сатып алганда тотылган акчаның 13 процентын кире кайтарып була. Ипотека кредитын рефинанслаганда бу акчаны элеккечә үк кире кайтарырга мөмкин. Ә менә берничә кредитны берләштереп, яңа кредит алганда алай эшләп булмаячак.

Инвалидлык биреләме?

Крон авыруы һәм I типтагы шикәр чире диагнозы куелган кеше инвалидлык рәсмиләштерә аламы?

Әлфия ХӘБИБУЛЛИНА. Апас

Татарстан медицина-социаль экспертиза бюросы белгече Резеда Абдразакова:
– Монда чирләрнең санынннан бигрәк, аларның организмга ясаган тискәре йогынты исәпкә алына. Әгәр теге яки бу чир аркасында организмның эшчәнлеге, әгъзаларның функцияләре бозылган, кешегә хәтта дарулар да булышмый башлаган икән, бу очракта ул инвалидлыкка дәгъва кыла ала. Әмма болар бар да махсус комиссия узгач, белгеч тарафыннан расланган булырга тиеш. Шуңа күрә сезгә теркәлгән урыныгыз буенча хастаханәгә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Табиб барлык тикшеренүләр, диагностик, дәвалау чараларыннан соң, медицина-социаль экспертиза бюросына юллама бирәчәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Укучы сүзе

«КАДЕРСЕЗ ЛИТРЛАР» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Сөтчелек тармагын бетерү максаты инде бу. 1 литр сөт өчен хуҗалыкка аз дигәндә 45–50 сум түләнергә тиеш. Хөкүмәт катышсын, салым түләүчеләрнең акчасын юк-барга әрәм иткәнче, сыер асрауны күтәрергә вакыт! Ә ник авылларга газ, су керттеләр, асфальт җәйделәр, экономикасын бетерделәр диярлек? Кем җавап бирер?

ФИРДӘВЕС

***

Авыл халкын бигрәк мыскыл итәләр инде. Хөкүмәт үзе булышасы урынга. Кибеттәге порошок сөтнең дә бер литры 100 сум бит. Аннан сөт исе дә килми. Авылда яшәп, мал асраучыларга медаль бирер идем мин.

Фирүзә НӘҖМИЕВА

***

Бензин бәясен дә шулай бер көндә 5 сумга төшерсәләр, бик әйбәт булыр иде!

Рушан ХИКМӘТОВА

***

Авылларны бетерергә маташалар. Менә дигән колхозларны бетерделәр. Кибетләрдә әйбер кыйбат. Авыл кешесенең хезмәт хакы да аз инде.

Римма КАМАЛЕТДИНОВА

«ГОМЕР ИТҮЕБЕЗГӘ – 60 ЕЛ, БЕЗГӘ АКЧА ТИЕШМЕ?» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Йа Аллам, соң ул акчаны сезнең кесәләрдән алып бирмиләрдер бит аларга? Бу нинди бер таныш түгел кешеләргә дә нәфрәтләнү соң? Кайдан килә шундый тар күңеллелек? Сез дә алырсыз, вакыты җиткәч. Чит кешеләр өчен дә сөенергә өйрәнегез. Барыбызны да Аллаһ яраткан, барыбызны да күреп, тоеп тора, гөнаһлы булмыйк юкка-барга нәфрәтләнеп, көнчелек, хөсетлек дип атала сезнең ул күпсенүегез.

МАЯСОРУР

***

Үз бәхетләрен күрә белмәгән кешеләр безнең илдә генәдер ул. Бергә яшәгән өчен акча? Тагын ни кирәк икән аларга? Правнукларының ипотекасын түләргә акча сорыйлармы икән?

Аноним

***

Сөбханалла! Дөрестән дә, Аллаһы Тәгалә бүләге бу. Иңне иңгә куеп, 60 ел гомер юлы үтелгән. Күпләр сокланырлык. Гаепләрлек берни дә юк монда. Бүләк бирүләре хак микән, дип сораганнар гына бит. Хәерле, тигез гомер сезгә, дияргә генә кала.

АЙСЫЛУ

***

60 ел бергә гомер иттек дип Аллаһка шөкер итеп, Аллаһка рәхмәтле булып яшәүдән бигрәк, акча өмет итеп утыралар. Оят та түгел. Бергә яшәгән өчен акча таптыра башладылар, шаккатмалы. Күпләргә бит бергә-бергә шулай озак гомер итү бәхете тәтеми.

Аноним

«ХОЛЫКСЫЗ ҖӘЙ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Без онык белән быел Нальчик шәһәрендә ял иттек. Таулар арасыннан төшкән елгада су коендык. Суда да еланнар кешедән, балалар тавышыннан, тракторлар эшләгән тавышлардан курыкмыйча, таш астыннан чыгып, безнең белән су керделәр. Галәмәт күренеш!

Халисә ХӘЕРТДИНОВА

«БАР ОСТАЛЫГЫ – БЕР КУЛДА» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Молодец инде. Хәзер ике кул белән дә юкны бушка әйләндерүче ирләр бик күп. Сәламәтлеген бирсен инде, Ходаем.

Рәмзия ФӘЙЗРАХМАНОВА

22 август | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 16.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 12+
10.00, 23.30 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА-2» 12+
11.00 «Татар халык җырлары» 0+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.00 «Бердәм булыйк». Якупова Гөлнара Идрисовна 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
17.00 «Татарлар» 12+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00, 20.00, 01.10 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Соотечественники» 12+
00.45 «Каравай». № 37, Кладези народного творения
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Шагыйрь Зөлфәт турында телеочерк 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Ватандашлар». Ренат Акчуринның йөрәкле командасы 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.20 «Бердәм булыйк» 6+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Яңалыклар» 12+
23.05 «Башваткыч» 12+
00.00 «Яңалыклар» 12+
00.40 «Татарлар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Башваткыч» 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Юлия Пересильд, Александр Устюгов, Сергей Пускепалис. «ЗОЛОТАЯ ОРДА» (S) 16+
23.45 «Большая игра» 16+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер» 12+
23.55 «ГОДУНОВ» 16+
01.05 «МОРОЗОВА» 16+
02.50 «СРОЧНО В НОМЕР!» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.35, 14.55, 20.55 Новости
06.05, 21.00, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 «ВЫШИБАЛА» 16+
11.00 VII Армейские Международные игры «АрМИ – 2022». Танковый биатлон 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40 Специальный репортаж 12+
13.00 Бокс. Bare Knuckle FC. Майкл Пейдж против Майка Перри. Трансляция из Великобритании 16+
14.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
15.00 «Громко». Прямой эфир
15.55 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Сампдория» – «Ювентус». Прямая трансляция
00.30 Тотальный футбол 12+
01.00 «КЛЕТКА СЛАВЫ ЧАВЕСА» 16+
02.55 Новости 0+
03.00 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Плавание 0+
04.10 «Наши иностранцы» 12+
04.40 «Человек из футбола» 12+
05.10 «Громко» 12+

НТВ

05.00 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
02.00 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Хороший дядя» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.00 «Верну любимого» 16+
14.30 «Преступления страсти» 16+
18.45 «Скажи, подруга» 16+
19.00 «МОЯ ЛЮБИМАЯ СВЕКРОВЬ» 16+
23.00 «Порча». «Ненасытность» 16+
23.35 «Знахарка» 16+
00.05 «Верну любимого» 16+
00.35 «Понять. Простить» 16+
01.30 «Тест на отцовство» 16+
03.10 «Давай разведёмся!» 16+
04.00 «6 кадров» 16+
04.25 «Преступления страсти» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «ВНИМАНИЕ, ГОВОРИТ МОСКВА!» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 23.25 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «ОГНЕННАЯ ДУГА» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.15, 21.00 Дневник АрМИ – 2022
13.35 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.10 «Курская дуга». Док. сериал 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Малоизвестные морские бои». Док. фильм. «Защита острова Сухо». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века». Док. сериал «Агент Мюрат. Роковая любовь» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
01.20 «ЕСЛИ ВРАГ НЕ СДАЕТСЯ…» 12+
02.35 «НЕБЕСНЫЙ ТИХОХОД» 12+
03.55 «БЕЗ ПРАВИЛ». 1-я и 2-я серии 16+

23 август | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА-2» 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.00 «Бердәм булыйк». Ирек Зиннуров 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Чужие берега. Садри Максуди 12+
00.40 «Каравай». Старинные тюрко-татарские инструменты 6+
01.10 «Уроки истории». Общественно-политическое движение в начале XX века 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Родная земля» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Нур сибелгәндә». Татарстанның халык артисты Дания Нуруллина турында телеочерк 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.20 «Бердәм булыйк» 6+
19.35 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
21.00 «Яңалыклар» 12+
00.00 «Яңалыклар» 12+
00.40 «Татарлар» 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.45 «Большая игра» 16+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер» 12+
23.55 «ГОДУНОВ» 16+
01.05 Детектив. «МОРОЗОВА» 16+
02.50 «СРОЧНО В НОМЕР!» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.35, 14.55, 20.55 Новости
06.05, 15.00, 21.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 «ВЫШИБАЛА» 16+
11.00 VII Армейские Международные игры «АрМИ – 2022». Танковый биатлон 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40 Специальный репортаж 12+
13.00 «Поединок». Художественный фильм. США, 2021 г. 16+
15.55 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. Раунд плей-офф. «Црвена Звезда» (Сербия) – «Маккаби» (Хайфа, Израиль). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. Раунд плей-офф. «Виктория» (Чехия) – «Карабах» (Азербайджан) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Плавание 0+
04.00 «Правила игры» 12+
04.30 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. Обзор тура 0+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.40 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
01.55 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «На волоске» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «Преступления страсти» 16+
19.00 «МОЯ ЛЮБИМАЯ СВЕКРОВЬ 2» 16+
22.45 «Порча». «Подарок из прошлого» 16+
23.20 «Знахарка» 16+
23.50 «Верну любимого» 16+
00.25 «Понять. Простить» 16+
01.20 «Тест на отцовство» 16+
03.00 «Давай разведёмся!» 16+
03.50 «6 кадров» 16+
04.25 «Преступления страсти» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «БЕЗ ПРАВИЛ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 00.45 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «ПРОРЫВ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.15, 21.00 Дневник АрМИ - 2022
13.35 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.10 «Сталинградская битва». Док. сериал 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Малоизвестные морские бои». Док. фильм. «Защита Северного морского пути». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого». Премьера! 16+
22.30 «Между тем» 12+
22.45 Танковый биатлон-2022. Эстафета. Полуфинал
02.15 «РУССКАЯ РУЛЕТКА (ЖЕНСКИЙ ВАРИАНТ)» 16+
04.00 «Легендарные самолеты. Су-25. Огнедышащий «Грач». Док. фильм 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Гыймадиева** Наҗия Сәлах кызы, Казан шәһәре Идел буе районының «Сыйныфтан тыш эш үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе бүлеге мөдире **Коткова** Татьяна Васильевна, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Советлар Союзы Герое В.Х. Хаҗиев исемендәге 7 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм туган әдәбият укытучысы **Хәмидова** Зөлфирә Зәки кызы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы **Афанасьева** Рәисә Вәли кызы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Г.С. Боровиков исемендәге 3 номерлы Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Евланова** Александра Федоровнага, «Зеленодольск механика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Муханов** Виктор Семеновичка, Казан шәһәре Идел буе районының «129 номерлы рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Хәбибуллина** Зөлфия Мөдәррис кызына, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире **Шәмсетдинова** Рәсимә Равил кызына **«Татарстан Республикасының халык укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Норма урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы **Әсәдуллина** Энҗе Васил кызына, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 2 номерлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Белоусова** Мәүлидә Идрис кызына, «Татарстан Республикасы Буа шәһәренең М.М. Вахитов исемендәге гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башлангыч сыйныфлар укытучысы **Гыйззәтуллин** Шәүкәт Салих улына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мамадыш шәһәренең 1 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең химия һәм биология укытучысы **Гыйлаева** Лилия Мөдәррис кызына, Чаллы шәһәренең «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 32 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең технология укытучысы **Демидов** Олег Николаевичка, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Югары Әлморза төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең технология укытучысы **Нотфуллин** Марс Нурулла улына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы **Хуҗина** Гөлназ Рәфис кызына, Казан шәһәре Вахитов районының «Советлар Союзы Герое А.С. Умеркин исемендәге 116 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган (татар) тел һәм әдәбият укытучысы **Габдинова** Зилә Әфтәх кызына, «Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Гарипова** Гөлнара Фидаил кызына, Казан шәһәре Мәскәү районының «Ж.А. Зайцева исемендәге 122 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбият укытучысы **Ибәтуллина** Рузилә Рәүф кызына, «Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең мәгариф идарәсе гомуми белем бирү бүлеге баш белгече **Миначова** Наилә Гадел кызына, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты **Фәтхуллова** Кадрия Сөнгать кызына, Казан шәһәре Киров районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 70 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбият укытучысы **Хафизова** Гөлия Самат кызына **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ДОШМАН КҮРӘСЕ ТҮГЕЛ

Кортизол – организмдагы иң мөһим гормоннарның берсе. Тынгысыз, стресска бай хәзерге заманда аның турында шактый еш ишетергә туры килә. Ул нәрсә өчен җавап бирә? Организмда кортизолның түбән яки югары булуын нинди билгеләр буенча ачыкларга?

Табиб-эндокринолог Роза КУЗНЕЦОВАның бу уңайдан фикерләрен тәкъдим итәбез.

➤ Медицина телендә кортизол дип йөртелгән гормонны икенче төрле стресс яки курку гормоны дип атарга мөмкин. Ник дигәндә, кеше бик нык курыкканда, эмоциональ һәм физик киеренкелек вакытында бөер өсте бизләре нәкъ менә шушы гормонны бүлеп чыгара. Ул бүленеп чыкканда, кешенең йөрәк тибеше ешая, кан басымы күтәрелә, кандагы шикәр күләме арта. Кыскасы, организм тиз арада көрәшкә әзерләнә. Шуңа күрә күпләр бу гормонны дошман күрә. Организмны даими рәвештә киеренке халәттә тотып, эштән чыгара, янәсе. Әмма бу алай түгел.

➤Кортизол гормоны майларны – май кислотасына, соңрак глюкозага әверелдерә. Соңгысы иң шәп энергия чыганагы санала. Стресс вакытында организмга ике тапкыр күбрәк энергия таләп ителә. Шул рәвешле кортизол организмны даими рәвештә энергия белән тәэмин итеп тора. Моннан тыш ул баш мие эшчәнлеген дә яхшырта. Организмны инфекцияләрдән саклый.

➤Организмдагы кортизол дәрәҗәсе көн дәвамында үзгәреп тора. Әйтик, иртән йокыдан уянганда, ул югары була. Аннары көн дәвамында акрынлап төшә башлый. Шуңа күрә анализлар дөрес нәтиҗә бирмәскә дә мөмкин. Гомумән, организмдагы кортизол күләмен кан анализы буенча гына ачыклап бетерү кыен. Шуңа күрә аның күләмен төкерек яки сидек анализы нигезендә билгелиләр.

Организмдагы кортизол күләмен көйләү

– Кәһвә һәм энергетик кебек эчемлекләрне кулланмау хәерле. Бер чынаяк кәһвә организмдагы кортизол күләмен 30 процентка арттыра. Бу инде күптән исбатланган.

– Тәмәке тарту, исерткеч эчемлекләр куллану кебек начар гадәтләрдән дә арыну хәерле.

– Стресстан сакланыгыз. Моның өчен начар яңалык-хәбәрләрне азрак тыңларга, начар уйлардан арынырга кирәк. Болар бар да кортизол күләмен бермә-бер арттыра.

– Вакытында ятып, вакытында уянырга өйрәнегез. Кеше көненә ким дигәндә 7–8 сәгать йокларга тиеш. Йокларга ятарга 1–2 сәгать кала телевизор, гаджетларны сүндереп куегыз.

Кортизол күләменең артык зур яки түбән булуы да начар. Ул һәрчак нормада булырга тиеш:
- •1 яшькә кадәрге балалар – 30–966 нм/л,
- •6 яшькә кадәрге балалар – 30–718 нм/л,
- •6–10 яшьлекләр 30–1049 нм/л,
- •11–15 яшьлек үсмерләр – 130–400 нм/л,
- •16–38 яшьлекләр – 130–600 нм/л,
- •өлкәннәр – 130 нм/л дан кимрәк.

– Туклану да әһәмияткә ия. Анда составында кортизолны киметә торган полифенол булган (яшел чәй, кара шоколад, миндаль, какао һ.б.) продуктлар булырга тиеш. Шикәр күләмен дә киметү хәерле.

– Көн дәвамында су эчеп тору, спорт белән шөгыльләнү дә организмдагы кортизол күләмен нормага тотарга ярдәм итә.

– Омега 3, В витамины, магний да кортизолны көйләргә ярдәм итәчәк.

КОРТИЗОЛ БИЛГЕЛӘРЕ

Югары	Түбән
– хәтер начарлану	– ябыгу, аппетит югалу, чәч коелу
– психик халәтнең тотрыклы булмавы	– хәлсезлек, баш авырту
– кандагы шикәр нормадан артык	– түбән кан басымы
– эрекция киму	– аң югалту
– йокысызлык	– күңел болгану, косу
– матдәләр алмашы начарлану, тазару	– тән тиресендәге тонык таплар
– сөякләр ныклыгы югалу	– ярсучанлык, күңел төшенкелеге
– инфекцияләргә тиз бирешүчәнлек	– хатын-кызларда җенси теләк булмау

Файдасы бар, белегез!

Картаюны акрынайта

Глюкоза, фруктоза, органик кислоталардан – кузгалак, лимон, янтарь, алма, шәраб кислоталары, пектин, С, Е һәм В төркеменә керүче витаминнарга бай помидорда кан ясалышында катнашучы фолий кислотасы да күп. Моннан тыш аның составында күзләргә уңай йогынты ясаучы каротин да бар.

→Помидор матдәләр алмашын яхшырта. С һәм А витаминына бай булганлыктан, иммунитетны ныгыта.

→Помидор ашарга яраткан кеше акрынрак картая, ди галимнәр. Ник дигәндә, ул организмдагы кислота-селте балансын җайга салырга ярдәм итә.

→Помидор составындагы «ликопин» дигән матдә яман шеш күзәнәкләре үсешен тоткарлый. Ул бик көчле антиоксидант санала, яман шешне генә түгел, йөрәк-кан тамырлары авыруларын да булдырмый. Ликопин термик эшкәртү узган помидорда яңа өзелгәнендәгегә караганда күбрәк була. Никадәр озаграк пешерсәң, ликопин да шулкадәр күбрәк туплана. Шуңа күрә дә өйдә ясалган кетчуп, томат согы, томат соусларын куллану да файдалы.

→Помидор йөрәк авыртудан файдалы. Бу аның калийга бай булуы белән аңлатыла. Билгеле булганча, йөрәк мускуллары ныклыгы өчен организмга калий кирәк.

→Составында тимер күп булганлыктан, помидор азканлылык вакытында да булыша.

→Кичкә, аякларыгыздагы кан тамырлары бүртеп, аякларыгыз сызлый икән, помидорны изеп, боламык хәлендә китерегез дә төнгә аякларыгызга шуны бәйләп ятыгыз. Файдасын шунда ук сизәрсез.

→Кәеф төшкән вакытта да помидор ашарга киңәш ителә. Ник дигәндә, анда бәхет гормоны – серотонин күп. Өлгергән помидорда «тиамин» дигән матдә дә бар. Кеше организмына кергәч, ул серотонинга әверелә. Помидор депрессиядән котылырга да булыша.

→Ябыгырга теләүчеләр өчен помидордан да яхшысы юк. Аның составында хром бар. Шуның аркасында помидор ашагач, тамак тиз туйган кебек була, ашыйсы килү бетә. Ә 100 грамм помидорда нибары 200 килокалория бар.

Үкчә шешен ничек дәваларга?

◆Йөргәндә аяк авыртмасын өчен, шешкә фольга (алюминийлы кәгазь) кисәге ябарга була. Үкчә шешенә (пяточная шпора) прополистан компресс та ябарга. Аны чәйнәп йомшарткач, авырткан җиргә төнгелеккә бәйләп куярлар.

◆Тоз + чәй содасы. Аяк түзәрлек эссе суга 3–4 аш кашыгы тоз һәм сода салып, су суынганчы аякларны тыгып утырырга. Соңыннан аякларны корытып, махсус мазь сөртергә.

◆Суган + сарымсак. Компресс өчен бер баш суган һәм 3–5 тырнак сарымсак изеп, үкчәгә ике сәгатькә куярга.

◆Серкә + тавык йомыркасы. Бер йомырканы сытып, ярты стакан 9 процентлы серкәгә салырга һәм 100 г атланмай кушып, әкрен утта куе мазь булганчы эретергә кирәк. Шуны төнгелеккә куясы.

◆Чи бәрәңге. Кыргычта кырып, һәр кичне үкчәгә куярга.

◆Тоз + 1 чәй кашыгы бал + 2 тамчы йод. Куе катнашманы авырткан үкчәдә ярты сәгать тотарга.

ВИТАМИНЛЫ ЧӘЙЛӘР

(Үләннәр белән дәвалаучы халык табибы Фирая Захарова рецептлары)

Күпьеллык тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтә алам: аерым бер үләнне генә файдалануга караганда, берничә үләнне бергә куллану нәтиҗәлерәк. Дару үләннәреннән ясалган төнәтмәләр һәркемгә индивидуаль рәвештә ясалса да, шифалы үләннәрдән витаминлы чәйне һәркем ясый ала. Иң элек бераз гөлҗимеш, дүләнә (боярышник), укроп, бөтнек, бака яфрагы, ромашка яфракларын ваклап, шуларга бераз тал кайрысы салып, чәй кебек кайнатып эчәргә мөмкин. Күрәгә, өрек, финик, инжир, йөземгә бераз гөлҗимеш салып, лимон һәм дарчин өстәп кайнатылган чәйнең дә шифасы әйтеп бетергесез. Соңгыларына бераз карлыган яфрагы өстәсәң дә була. Бер ясалган чәйгә кайнар су өсти-өсти өч көн эчәргә мөмкин.

Кавыктан коткаручы маска

Бу масканы ясаганда суган, сарымсак һәм лимон ярдәмгә киләчәк. Беренче масканы ясау өчен, уылган бер баш суганга 2 аш кашыгы аракы һәм 1 аш кашыгы кастор мае кушып болгатырга кирәк. Икенче төрлесен ясау өчен, уылган бер тырнак сарымсакка 100 г җылытылган әрекмән мае кушасы. Өченче маска 4 аш кашыгы зәйтүн мае 1 аш кашыгы лимон согы кушып ясала. Бу маскаларны баш тиресенә сылаганнан соң, полиэтилен пакет киеп, бер сәгатьтән соң гына юып төшерергә кирәк.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

«БАЛ» ДИГӘЧ, БАЛЛАНМЫЙ

Кышка бал хәстәрен күреп кую чоры. Әмма үзең яки туганың, дус-танышың умартачы булмаганда, чын балны табу бик җиңел эш түгел. Исеме еш кына җисеменә туры килмәскә мөмкин чөнки. Тикмәгә генә иң еш ялганлап җитештерелүче продуктлар унлыгына керми ул. Татлы ризыкны лаборатория шартларында тикшереп карау күпчелек очракта тискәре нәтиҗә бирә, дип шиккә сала белгечләр.

«Татар-информ»

Балык Бистәсеннән умартачы Нияз Хәйретдинов та белгечләр сүзләрен хуплый. Аның сүзләренчә, хәзер, чыннан да, балны бик җиңел җитештерүчеләр күбәйгән. Иң гади ысулы – умарта кортларына шикәрле су ашату. Мондый очракта продуктның өчтән бер өлеше генә балдан торачак. Калганы – шикәр. Сәламәт кешегә баллы суның зыяны булмас, әлбәттә, әмма файдасы да юк. Ә бит бал – файдалы матдәләр «келәте» булырга тиеш.

Татып карадым – берни аңламадым

Шикәр комы, су, крахмал, он... Намуссыз умартачылар балга әнә шуларны кушып сатарга да күп сорап тормый. Ә чын балның билгеләре нинди? Аны ничек ялганыннан аерырга? Ярминкәгә килүчеләргә, гадәттә, түмән татып карарга киңәш итәләр. Әмма таныш умартачыбыз әйтүенчә, болай гына берни дә белеп булмый. Балның тәме авызда 40 минутлап саклана, ә берничә сортның түмән татыгач, барысы бергә кушылып, беренче тапкыр кабып каралганы иң тәмлесе булып тоела.

Шулай да, аның әйтүенчә, лабораториягә бармыйча, мөстәкыйль генә дә чын продуктны ялганыннан аерырга мөмкин. Кул чугының өске өлешенә бер тамчы бал тамызып, крем кебек сылагыз. Чын бал, әйбәт крем сыман, сеңеп бетәчәк. Иренмәсәгез, даруханәдән көмеш нитратлы карандаш (ляписный карандаш – тән тиресен дәвалау өчен кулланыла) алып, шуның ярдәмендә балга шикәр комы кушылганмы-юкмы икәнен белергә була. Суга бал салып, эремә ясагыз да бераз гына ляпис өстәгез. Савытта ак утырма пәйда булса, бал чын түгел дигән сүз.

Ясалма бал катмый, шикәрләнми. Шуңа күрә намуссыз җитештерүчеләр аңа он һәм крахмал өсти. Бер тамчы балга йод тамызыгыз: кирәкмәгән ингредиентлары булса, продукт шундук зәңгәрләнәчәк.

Исе дә исе!

Исенә дә игътибар итәргә кирәк. Ялган продуктның исе баллы суныкы яки бозлы кәнфитнекенә охшаш. Өсте ачык торган чын балның исе беленер-беленмәс кенә була. Ярминкәдә бал ачык савытларда сатылган очракта, сатучыдан аны кашык белән болгатып каравын сорагыз. Болгатканда, чын балның исе көчәя.

Үтә күренмәле булсын

Нияз әфәнде әйтүенчә, табигый бал, шикәрләнгәнче, үтә күренмәле була. Банкадагы балның асты катып, өсте сыек килеш калса, бу «дөрес» бал түгел: тулаем шикәрләнергә тиеш ул. Ә инде балның яңа аертылганмы-түгелме икәнен өстендәге ак күбегенә карап белергә мөмкин. Яңа бал бераз гына күбекләнеп торса, узган елгы эретелгәненең күбеге зуррак, сабын күбегенә охшабрак тора һәм тәме дә әчкелтрәк була.

Гадәттә, без матур, сыек балга мөкиббән китәбез. Ә утырганын, шикәрләнгәнен читкәрәк этәбез. Ләкин сыйфатыннан шикләнүчеләргә нәкъ менә шундыен сатып алу хәерлерәк, ди тәҗрибәле умартачы.

Аш-су

«ИХ, ҖӘЙ!» САЛАТЫ

Илсөя Шәйхетдинова рецепты

Кирәк: *яртышар кило кызыл һәм сары татлы борыч, 2 ташкабак (уртача зурлыкта – цукини булса, тагын да әйбәтрәк), тәменчә петрушка, сельдерей, кинза, 1 аш кашыгы тоз, 2 литр су, 50 мл уксус, 4 аш кашыгы шикәр комы, 1 баш сарымсак, тәменә карап, хуш исле түгәрәк борыч.*

Борычны юып, орлыкларыннан чистартабыз һәм кисәкләргә турыйбыз. Ташкабакны юабыз. Яшен чистартмаска да мөмкин. Өлгергәннәренең кабыгын әрчеп, бөҗралап турыйбыз. Сарымсакны тырнакларга аерып чистартабыз. Яшел тәмләткечләрне юып ваклыйбыз. Яртышар литрлы яки зуррак банкаларны стерильләштерәбез, тимер капкачларны кайнатабыз. Сарымсактан кала бөтен яшелчәләрне кәстрүлгә тутырып, су, серкә, тоз һәм шикәр комы өстибез һәм кайнатып чыгарабыз. Шуннан соң тагын 15 минут сүрәнрәк утта тотабыз. Уттан алып, яшелчәне банкаларга тутырабыз, һәркайсына бер-ике тырнак сарымсак, яшел тәмләткеч, хуш исле түгәрәк борыч өстибез. Маринад агызабыз һәм тимер капкач белән борып ябабыз.

Киңәш-табыш

Киндерне үтүкләү сере

Эссе җәй дәвам итә. Шуңа әле һаман табигый тукымадан – киндердән тегелгән кием-салымны ешрак кияргә тырышабыз. Тик аны үтүкләү генә – бер бәла! Әшне җиңеләйтүнең бер ысулы бар. Чиста, коры киемне җылы сулы ләгәнгә салып, бераз кондиционер өстибез. Шуннан машинага салабыз. Юуга түгел, ә сыгу режимына куябыз. Машина эшен тәгәлләгәч, киемне үтүклибез. Үтүкләүгә үк кимибез. Киемне берәр сәгать чамасы «плечик»ка элеп тоту әйбәт. Болай эшләгәндә, ул тиз бөгәрләнмәячәк.

Бакчачы почмагы

Сорауларга бакчачы-блогер Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә.

:: Беренче тапкыр бакча җиләге утыртырга йөрим. Вакыты җитте бугай...

Эльвира ДМИТРИЕВА. Казан

– Августның икенче яртысында җиләк үсентеләре утыртыла, моның өчен болытлы көнне туры китерү әйбәтрәк. Җиләкне кыяр, помидор, борыч, кәбестә, баклажан үскән җиргә утыртырга ярамый. Моның өчен борчак, фасоль, редиска, әче торма, суган, сарымсак, кишер, рапс, горчица җире кулай. Кара балчыклы яхшы җир икән, утыртканда, чокырына бераз черемә салып, туфрак белән бутагыз. Авыр, кызыл балчыклы җиргә черегән агач чүбе белән мочевина кертергә кирәк (1 кв. м мәйдан өчен: 10 кг черегән агач чүбенә 1 стакан көл салырга, 2 литр суга 2 аш кашыгы мочевина салып эретергә һәм барысын бергә болгатырга). Шулай ук елга комы (1 кв. м мәйданга 2,5 чиләк) яки торф белән көл (1 кв. м мәйдан өчен: 1 чиләк торфка 1 стакан көл кушарга) кертергә мөмкин. Ә инде бик начар туфраклы бакчаны 1 кв. метр мәйданга 1 чиләк черемә, 1 аш кашыгы калий сульфаты, 2 шырпы кабы суперфосфат, 50 грамм мочевина белән ашлау яхшы.

:: Алма, сливаларның кайберләре ботагында череп утыра. Нилектән икән?

Зөлфия ӘХМӘТШИНА. Аксубай

– Җимеш череге (плодовая гниль) белән зарарлануга бәйле бу. Мондый агачны иртә яздан бакырлы препаратлар (бордо катнашмасы, хом, хорус) белән дәваларга кирәк. Күзен черек җимешләрнең берсе дә агачта калмасын. Җиргә коелган барлык җимешләре һәм яфракларын юкка чыгару шарт.

Укучыбыз киңәше



Өлгергәнме?

Кайчандыр бер фәнни-популяр журналда карбызның өлгергәнлеген билгеләүнең математик ысулы турында укыган идем. Авырлыгының карбыз әйләнәсе озынлыгына карата нисбәтеннән чыгып билгеләнә икән ул. Якынча күрсәткечләре таблицасы мондыйрак.

Авырлыгы (кг)	Әйләнәсе озынлыгы (см)
2	49
4	62
6	71
8	78
10	84

Карбызның авырлыгын һәм «корсагы» әйләнәсен үлчибез (озынчасын ике урыннан үлчәп, уртача күрсәткечне алабыз).

Билгеле бер авырлыктагы карбызның әйләнәсе озынлыгы таблицада күрсәтелгәннән кимрәк икән, димәк, өлгермәгән. Күрсәткечкә туры килсә яки аннан зуррак булса – өлгергән. Ә инде күпкә зур булса – артык өлгергән (чери дә башлаган булырга мөмкин), дигән сүз.

Зиннур МАНСУРОВ. Казан

АЛЛАҺ КҮРСӘТКӘН ХАК ЮЛ

Ислам дине һәм мөселманнар турында калыплашкан ямьсез фикерләр шактый. Әйтик, бу дин кешеләрне мәҗбүриләү һәм чикләүдән кала башканы белми, мөселман кеше – террорчы һәм экстремист... Әлбәттә, дини белеме булган һәм иманы нык кеше мондый сүзләр әйтү түгел, андый фикерне башына да китермәс. Шулай да ислам дине – нинди дин? Диндә мәҗбүриләү бармы? Башкаларга хөрмәт белән карау турында ни диелә?

Әлеге һәм башка сорауларга җавапны Наил хәзрәт ЙОСЫПОВ белән бергәләп эзләдек.

:: Ни кызганыч, ислам дине турында ялгыш фикер йөртүчеләр очрап тора. Динебез турында мондый фикерләр кайдан чыга соң?

– Аллаһка шөкер, без – ислам динендә, без Аллаһка гына гыйбадәт кылып яшибез. Без сайлаган юлыбызны дөрес һәм хак дип сайлап алганбыз. Үзебезнең юлыбызның хак икәнен белеп, ул юлны башкаларга да күрсәтәбез. Без үзебезгә дөнья һәм ахирәт изгелеген теләгәнлектән, башкаларга да шуны телибез. Без башка диндәге һәм башка милләттәге кешеләргә газиз динебез турында сөйләгәндә, сүзебезне: «Ислам дине – тынычлык дине, ислам тынычлыкка өнди», – дип башлыйбыз. Ә ул дөрестән дә шулай.

Ислам дине ул – хак, дөрес һәм тынычлыкка-иминлеккә чакыра торган дин. Ләкин, ни кызганыч, кайберәүләр аны киресенчә аңлый. Алай дип әйтүчеләрне дә аңларга була. Ни өчен дисәгез, хәзерге вакытта мөселман илләрендә тыныч булмаган мохиткә, Татарстаныбызда, Россиядәге террорчыларның гамәлләренә карап, исламга карата хаталы бәя бирелә. Алар маңгай күзләре белән күргәннәреннән чыгып бәя бирсәләр, без, мөселманнар, авызыбызга су капкан шикелле дөрес сүзне әйтә алмыйча гаҗиз булып калабыз.

Безгә иң элек экстремизм һәм терроризм, афәт-бәлаләр булдырмас өчен, аңлату эшләре алып барырга кирәк.

:: Хәзрәт, ислам дине – нинди дин ул? Аның чын асылын аңлатып узсак иде.

– Ислам Аллаһы Тәгаләнең хак дине буенча гамәл кылу дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә тарафыннан Мөхәммәдкә (с.г.в.) иңдерелгән дин – ислам дине. Аллаһы Тәгалә аңа, кешеләрне яхшылыкка өйрәтер өчен, ислам динен биргән. Аның хөкемнәре буенча гамәл кылган кеше дөньяда да, ахирәттә дә даими рәхәтлектә һәм иминлектә булачак. Ислам диненең хаклыгына ышанган кеше исә мөэмин һәм мөселман дип атала.

:: Динебездә кан кою, җәбер-золым, башкаларны рәнҗетү, террористик, экстремистик гамәлләр турында ни диелә?

– Ислам – рәхимлек дине. «Бер кешене үтерүче барлык кешеләрне үтергән кебек булыр, бер кешене үлемнән коткаручы барлык кешеләрне үлемнән коткарган кебек булыр», – диелә Коръәндә.

Коръән сүрәләрен укып фикерләсәк һәм пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тормыш юлын өйрәнсәк, динебездәге рәхим-шәфкатьлелекне, кешелеклелекне, бер-береңә ярдәмчел булырга өндәүне күреп, гаҗәпкә дә калырбыз.

Мөселманга нинди генә зыян эшләсәләр дә, динебез начарлыкка яхшылык белән җавап кайтарырга чакыра. «Яхшылык илә явызлык бертигез булмаслар, чөнки яхшылыкта файда һәм савап бар, явызлыкта зарар һәм газап бар. Әгәр сиңа берәү явызлык кылса, син аңа җавап итеп яхшылык кыл, ул кеше сиңа явызлыкны дошманлык белән кыладыр, әмма син сабыр бул һәм аның явызлыгына каршы һәрвакыт изгелек ит, соңрак ул синдә явызлыкның юклыгын белеп, явызлык итүеннән туктар һәм, тәүбә итеп, синнән гафу сорар, аннары бер-берегезгә якын дус булырсыз. Ләкин бу эшне һәр кеше эшли алмас, мәгәр көчле иманлы, чын сабыр мөэминнәр генә эшли алырлар, һәм явызлыкка каршы изгелек итү һәрбер кешегә бирелмәс, мәгәр олуг бәхетле кешегә генә бирелер», – диелә «Фуссыйләт» сүрәсендәге аятьләрдә.

kzn.ru

Пәйгамбәребез (с.г.в.) кешеләргә зыян салу һәм борчу-мәшәкать тудырудан ерак булырга кушкан. Ул бер хәдисендә болай ди: «Гомумән, зарар китерү дә, җавап итеп зарар кайтару да тыела». Кешене түгел, хәтта хайваннарны да рәнҗетергә ярамый.

«Ислам дине – тынычлык дине», – дип сөйләп кенә калмыйча, аны гамәлдә дә исбат итәргә кирәк. Мөселманнар, яхшылыкка өндәп, үзләре үрнәк булырга тиеш булсалар да, барысы да алай гына бармый, күрәсең. Башка диндәге кешеләр арасында да караклар, кеше рәнҗетүчеләр, гайбәт сатучылар, ялган сөйләүчеләр һәм кеше үтерүчеләр юк түгел. Ислам дине шулай эшләргә кушамыни?

Чын мөселман андый булмас. Ислам дине үзеңә дә, кешегә дә зарар итәргә кушмый. Ислам дине тынычлыкка һәм бер-береңә ярдәм итәргә, изгелек кылырга өнди. Тыныч илдә яшәү рәхәт тә, күңелле дә.

:: Нишләп җинаятьчеләр Аллаһы Тәгаләне телгә ала, Коръән белән ант итә, шул рәвешле динебезне пычрата? Кешеләрне үтерүне «җиһад кылу» дип аклый?

– Бер гаепсез кешеләрне үтерү җәмгыятькә, үтерелгән кешеләрнең ата-анасына, туганнарына, якыннарына күпме зарар һәм кайгы китерә. Андый явызлыкның «динне алга җибәрү өчен», «дин өчен көрәш» дип, динебез исеменә яшеренеп эшләнүе аеруча кызганыч. Безгә динебезне ирештергән, Коръәнне аңлатып калдырган сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) дә «зарар китерү тыела» дип әйтеп калдырган бит. Шуны онытмаска кирәк: кеше йөрәге күтәрә алмаслык кайгы – иң зур зарарларның берсе.

Дин исемен үз явызлыкларына калкан итеп, кеше гомерен өзәргә чакыручы, шул явыз фикерләрен таратучы кешеләрне «мөселман» дип атарга һич кенә дә тел әйләнми. Алар берничек тә Аллаһы Тәгалә юлында йөрүче кешеләр була алмый, андыйлар – киресенчә, шайтан котыртуына ияреп, динебезгә бик каты зыян салучы!

«Аларга: «Җир өстендә фетнә чыгарып, кешеләр арасын бозмагыз», – диелсә, «Юк, без бозмыйбыз, бәлки төзәтәбез», – диләр. Аң булыгыз! Шул монафикълар – үзләре дә сизмәстән, кешеләр арасын бозып, җир өстендә фәсад кылучылар», – диелә «Әл-Бәкара» сүрәсенең 11–12 нче аятьләрендә.

:: Башкаларны хөрмәтләү, ярату, мәрхәмәтле булу турында динебездә нинди хәдисләр бар?

– Бу хакта хәдисләр бихисап. Мәсәлән: «Үзеңә нәрсә теләсәң, башкаларга да шуны телә», «Игелекле эшләрне тавышсыз гына башкарыгыз», «Һәр изгелек – садака», «Башкаларга мәрхәмәтлелек күрсәтмәгән кеше Аллаһның рәхмәтеннән ерак булыр».

Өч хәдис

«Хатын-кыз асылда кәкре кабыргадан яратылган, әгәр син аны төзәтергә дип тырышсаң сындырырсың, шуңа күрә аңа карата йомшак бул, аның белән тереклек кылырсың».

«Кеше кимчелеген фаш итсәгез, үзегездә дә шундый хата булмыйча, калмассез».

«Аң булыгыз! Сезнең иң көчлегез кем икәнен әйтимме? Ул – ачу вакытында үзен тота белүчегез».

Йәгез, бер дога

kzn.ru

БАЛА СОРАП УКЫЛА

«Рабби ләә тәзәрнии фәрдән вә әнтә хайруль-вәәрисиин».

Мәгънәсе: «Әй Раббым! Мине берүземне генә калдырма. Син – варисларның иң яхшысы».

Белеп тор!

Госел һәм аның фарызлары

Госел бөтен тәнне ышкып, юып коену дигәнне аңлата.

Госел алачак кеше түбәндәге эшләрне башкара:

1) әүвәл истинҗа кылып, гаурәтләрен пакьли;
– Бездә даруларның Россия аналоглары бик күп. Аларны илдәге үзгәрешләргә кадәр дә күп сата идек, чөнки иң беренче чиратта кеше арзанлы вариант булуын да белергә тиеш. Җитәкчелек тә шуны таләп итә. Даруларга аналог кына дип карамаска кирәк, – ди фармацевт. – Аның тәэсире төрле организмга төрлечә булырга мөмкин. Бер организмга килешмәгәне икенчегә бик уңышлы булуы бар. Кыйммәтлесе килешмичә, арзанлысының файдасын күрүчеләр дә бар. Хәзер халык үзе дә белемле, мәгълүматлы. Күп очракта җитештерүчесен сорап алалар. Кан басымы күтәрелү яки төшү белән интегүчеләрнең күпчелеге хәзер Россиядә җитештерелгән аналогларга күчте. Чөнки, беренчедән, чит илнекеләр бик нык кыйммәтләнде. Икенчедән, үзебезнекеләр һәрвакыт сатуда бар. Баштагы вакытларда чит ил дарулары булмаячак дип бик куркыткан нар иде. Шөкер, хәлләр алай ук катлаулы түгел.

Бәяләргә килгәндә, фармацевт әйтүенчә, даруларның бәяләре долларга карап үзгәргән.

– Ләкин артык зур аерма булды дип әйтмәс идем. Хәзер алар, киресенчә, төшә дә әле. Кыскасы, бәяләр гел уйнап тора, – диде ул.

КҮБРӘК БУЛСА, АРЗАНАЯ

Дару препаратлары юкка чыгарлык сәбәпләр юк. Нинди дер проблема бар икән, димәк, моның сәбәпләрен нык лап торып өйрәнергә кирәк. Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов әнә шулай ди. Аның сүзләренчә, бер генә фармацевтика компаниясе дә Россия базарыннан китү турында рәсми рәвештә игълан итмәгән.

– Бер генә компания дә Россиядән чыгып китмәде, бер генә завод та ябылмады һәм бер генә җитештерүче дә хәрби операцияләр аркасында дару ясаудан туктамады. Шуңа күрә кайбер препаратлар булмый торса да, вакытлыча гына. Мондый хәлләр башка вакытта да күзәтелә иде, – диде ул. – Хәзер аналоглары булмаган, алыштырып булмый торган дарулар бик аз. Заманча инновацион препарат барлыкка килү белән шунда ук аны алыштырып була торганын ясыйлар. Шуңа күрә бүген әлеге мәсьәләдә авырлыклар юк. Гомумән алганда, чит илдән барлык дарулар да керә. Әгәр дә кеше берәр препаратны таба алмый икән, аның сәбәпләрен ачыкларга кирәк.

Айрат Фәррахов әйтүенчә, чит ил даруларын үзебезнекеләр белән алыштыру буенча эш бара.

– Миңа калса, барлык дарулар ны да бары Россиядә генә эшләргә дигән бурыч куярга кирәкми, – ди ул. – Бу очракта препаратлар кыйммәтрәк булырга мөмкин. Шуңа күрә әлеге вакытта кабул ителгән стратегия дөрес. Бездә тормыш өчен аеруча мөһим булган 700 төрдә дару бар. Менә аларны тулысынча үзебезнең территориядә чыгарырга омтылырга кирәк. Ә калганнары алай ук мөһим түгел.

Депутат фикеренчә, иң мөһиме – дарулар кыйммәтләнмәсен өчен шартлар тудыру. Моңа ничек ирешеп була соң? Беренчедән, конкуренция булырга тиеш. Ә моның өчен даруларны алыштырып була торганнарын эшләргә кирәк. Шулай ук электрон заказ бирү, шул исәптән, рецепт буенча бирелә торганнарны да интернет аша алу мөмкинлеген булдыру мәҗбүри, ди ул.

Халык арасында даруларның аналогларына шик белдерүчеләр дә бар. Аларның фикерен Айрат Фәррахова да җиткердек. Ул әлеге мәсьәләдә кистерен җавап бирде:

– Россия дару препаратларын сертификацияләү буенча иң катлаулы илләрнең берсе булып тора. Базарга нәтиҗәсе булмаган, «эшләми» торган даруларны чыгару, теркәү мөмкин хәл түгел. Бу яктан закон бик көчле бездә. Шуңа күрә ялган эшләү мөмкин түгел диярлек. Менә инде берничә ел дару препаратларын маркировкалыйлар. Шуңа күрә контрафакт юк. Даруларны эшләү, базарга чыгару эше бик көчле контроль астында тора. Кайвакыт хәтта кирәгеннән артык кебек тә тоела. Шуңа күрә без кайбер очракларда таләпләрне киметүне дә сорыйбыз. Чөнки ул кайвакыт яңа препаратларны чыгаруны тоткарлый. Һәм бу нәтиҗәдә бәягә йогынты ясый. Дару никадәрле күбрәк булса, ул шуның кадәрле арзанрак.

Сәрия МИФТАХОВА

ИШЕЛМӘСЕН ТАУЛАР

«Чәүкә тавын казып бетерәләр, шуннан юлга балчык ташыйлар, моны ничек туктатырга була? Безнең өчен бик кадерле урын бит ул». Актаныш районының Чишмәбаш авылында яшәүчеләр редакциягә әнә шулай дип шалтыраттылар. Чишмәбашлыларны борчыган мәсьәләгә ачыклык кертү өчен, Актаныш районына кузгалдык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Торналар җыры...

Чишмәбаш авылы артык зур да, бик кечкенә дә түгел. Монда 60тан артык хуҗалык бардыр, төгәл генә әйтә алмадылар. Табигате матур. Торналар төшкән урыннары бар. Кошлар җылы якка киткәнне күреп елыйсылар килә хәтта, диләр. Авыл уртасыннан тауга юл күтәрелә. Монысыннан Әби патша үткән икән. Үзара салым акчасына шул юлны рәткә китерергә хыялланалар. Авылда мәдәният йортыннан кала, башка социаль объектларны күрмәдек. Автокибет атнага ике мәртәбә килә икән. Товарларны шуннан сатып алалар, кирәк булса, күршедәге Байсар кибетенә баралар. Шунысы гаҗәп тоелды: монда халык юл да, кибет тә, башкасын да сорамый. Гадәттә, авылга журналист килсә, барысын да әйтеп калырга тырышалар бит. Матди кыйммәтләргә әллә ни исләре китмиме шунда, әллә булганына шөкер итеп яшәргә өйрәнгәннәрме... Барысының да телендә – Чәүкә тавы. Тауны гына түгел, аның белән бергә авылның хатирәләрен дә саклап каласылары килә. Сүз уңаеннан, монда һәрбер тауның, урынның атамасы бар. Тимер тырнак, Каравыл тавы, Янган тау... Һәрберсендә яшьлек, авылның үткәне, тарих саклана.

Рәхәтләнеп яшә генә...

Чәүкә тавын казый башлаганга бер айлап чамасы үтеп, кызулыклары сүрелгәнгәме шунда, әллә холыклары тыныч булгангамы, бу хакта тыныч кына сөйлиләр. Чәчрәп чыкмыйлар, тавыш чыгармыйлар, әмма үз теләкләренә ирешәселәре килә.

Гөлүсә апа Гыймаева Чаллыда трамвай йөртеп, пенсиягә чыккач, туган авылына кайткан. Шәһәр ыгы-зыгысыннан арынып яши башлавына – 9 ел. «Монда буш йортлар аз, соңгы берничә елда гына да 11 йортка кеше кайтты. Пенсиягә чыккач, кеше авылга тартыла. Туган авыл табигате матур, Сөн елгасы ага, тирә-якта урманнар, аннан кайтып та кермибез. Аю тавышы ишеткәнче, урманнан чыккан булмады. Гөмбәсе, җиләге, мәтрүшкәсе күп. Туфрак әйбәт, нәрсә теләсәң, шуны үстерәсең. Яшә дә яшә генә», – ди Гөлүсә апа.

Актаныште яшәүче Ләйлә Ногманованың да җәе авылда уза, башка вакытта атна саен кайтып йөриләр. «Моннан киткән дә юк. Бик яратам авылымны. Урманнан кайтканда, чәчәк булса да җыеп кайтам. Чәүкә тавына менмичә калган көн юк. Тауны казый башлаганчы, авыл халкы шунда җыелып утыра иде. 1 Май саен бөтен балалар җыелып, Карга боткасы пешерә идек», – ди ул.

«Чәүкә тавы бик кадерле, аны яратмаган кеше юк. Кечесе дә, олысы да шуңа тартыла иде. Иң биек ноктасына беседка кордылар. Бәйрәмнәрдә учаклар ягып утырабыз. Моның өчен календарьда нindидер кызыл дата булу кирәкми. Самавыр куеп, чәй эчәбез. Элек пионер лагере оештырыла иде. Смена тәмамланган чакта, менеп, учак яга идек. Ул таудан бөтен дөнья күренеп тора. Тарихи җир дә әле ул. Аклар һәм кызыллар сугышканда, разведчикларның күзәтү урыны булган. Тау башында кызыллар зур йолдыз ясап куйган. Без бәләкәй чакларда егетләр аны яңартып та йөргән иде әле. Тик тарихи объектлар исемлегенә кермәгәч, моны ничек дәлиллисең? Без бит архивларда казынып утыра алмыйбыз», – дип сөйли Ләйсән Әхмәрова. Ә бер көнне авылда экскаваторлар пәйда була, «КамАЗ»лар балчык ташырга тотына. «Бездән беркем дә сорап тормады. Авыл җыенында: «Нигә алай эшлисез?» – дип елый-елый сөйләдек. Тимәсеннәр иде башка, тау тау булып калсын. Бөтен авыл халкына да кадерле ул», – ди Ләйсән ханым.

Чокылган тау...

Байсар авыл җирлеге башлыгы Рәмис Кадыйров һәм шушы авылда яшәүчеләр белән Чәүкә тавын урап кайттык.

– Чәүкәләр ияләшкәнгә, шулай дип кушканнармы? – дип сорыйм алардан.

– Чәүкәләр күп булгандыр, күрәсең. Авылда әллә ни күп күренми алар. Тарихын белмибез шул, – диделәр.

Менә ул – авыл халкы сагынып, борчылып сөйли торган Чәүкә тавы. Аның итәкләре чыннан да чокылган, балчык чыгару урынына әйләнгән. Тауга менә торган юлда балчык өеме ята. «Мин үрмәләп булса да мендем», – ди Гөлүсә апа. Янәшәсендә генә изге чишмә ага. Монда Актаныштан гына түгел, күршедәге башкорт авылларыннан да су алырга киләләр икән.

– Элек тә бу тау карьер булып кулланылган. Балчыкны кайдан алып була, шуннан алганнар. Эшләр туктатылган, тик урынны тигезләмәгәннәр. Монысына күптән инде. Быел җәй «Татавтодор» оешмасы юлларга түшәр өчен кызыл балчык ташыды. Без, алмагыз, дип әйтә алмыйбыз. Мин сораштым, хәзер инде башка кагылмаска, чокылган җирләрне тигезләп куярга вәгъдә бирделәр. Тарихи һәйкәл булыр өчен тарихи объектлар исемлегенә кермәгән ул. Киләчәктә Чәүкә тавын сакланыла торган урын (охранная зона) итеп эшлисе иде, – диде Рәмис Кадыйров.

«Татавтодор»ның Минзәлә филиалы директоры Марат Сәмигуллин белдергәнчә, бирелән республика программасы буенча төзелүче «Актаныш – Мөслим» юлына балчык ташыганнар. Байсардан Актанышка таба 4 чакрымлы юл бу.

– Юлларны да төзекләндермичә булмый бит, – ди ул. – Бу – безнең җир түгел. Авыл җирлегенеке ул. Таудан балчык алырга Татарстан Экология министрлыгы рөхсәт бирде. Бу хакта авыл җирлеге башлыгы да белә. Балчык алынган урынны сентябрь аенда тигезләп куячакбыз. Бу җиргә башка кагылмаячакбыз.

Актаныш районы хакимиятенең матбугат хезмәте белдергәнчә, тауның тарихи әһәмияте булмау сәбәпле, аны мәдәни мирас объекты итеп теркәп булмый. Тарихи чыганакларда язылганча, Гражданнар сугышы чорында аклар, шул тау өстенә урнашып, Минзәлә яклап килгән кызылармиячеләргә туптан атканнар. Бу бәрелештә авыл халкы уртада калган, әле һаман да, тирәнрәк сөрсәң, бакчаларда ядрә калдыклары табарга мөмкин. «Халык белән килешеп, саклау зонасы булярак теркәсәк кенә. Авыл халкы өчен бик якын, кадерле урыннар ул. Шуңа да якын арада бу мәсьәлә уңай хәл ителер, дип уйлыйбыз. Җирлек башлыгы белән сөйләшү булды», – диделәр матбугат хезмәтендә.

Тау тау булып калсын... Күпне сорамый бит Чишмәбаш халкы. Чәүкә тавында самавыр куеп, чәй эчеп, җырлашып утыруларын дәвам иттерсеннәр. Учагы да янсын, аның яктысында үткәннәрне сагынып искә алсыннар. Күңел хакы өчен күп кирәкмени? Шушы тау башына менеп, авылым бетми бит әле, кайчандыр киткәннәр, үз вакыты җиткәч, барыбер бер кайта бит, дип тынычлансыннар. Тауның җимерелгән ягы, туфрак салгач, вакыт белән үз халәтенә кайтыр анысы. Тик дөнья байлыгына кызыкмаган, чишмә суы кебек саф күңелле Чишмәбаш халкының гына күңеле кителеп калмасын иде.

ТУКСАНДА ДА ТУКТАМЫЙ

Туган көне дә, башаклар тулып, иген кырларында комбайннар гөрелтесе кызган вакытларга туры килә икән Наил ага Сабировның. 34 ел буена бер колхозны җигелеп тартканда да, райкомда, профсоюзда төрле вазыйфалар башкарып, күзәтү, ярдәм итү нияте белән басуларны иңләгәндә дә, бәйрәм дип уйларга вакыты да булмагандыр, бәлки.

Идар Мөхәммәтҗанов

Фотога төшергәндә күзәтеп торам: алмалы бакчалары Наил ага белән Ләлә апага бигрәкләр дә килешеп тора. Яшь парлардан бер дә ким түгел. «Бер-береңне аңлап, яратышып торгач, яшәүләре дә рәхәт бит», – дип, Наил абый хәләле ягына кабат-кабат күз ата.

Хәер, хәзер дә шундый әле ул. Быел 20 августта 90 яшь тула үзенә. Эштән туктаганы юк. Улы Илһам җитәкләгән «Татнефтепродукты» оешмасында киңәшче вазыйфасын башкара. Инде күп еллар туган җире – Әтнә районындагы Дусым авылының килечәген кайгыртып, чын күңелдән янып-көеп йөри. Юбилей алдыннан без дә Наил аганың хәл-әхвәлләрен белешеп кайтырга булдык.

Таяныч

Сугыш еллары. Яңасы җитмәгән, искесе беткән вакыт. Өйдә дүрт бала. Әтиләре – сугышта, әниләре – көн-төн фермада. Сеңлесе Кәүсәрия, илереп-илереп, ашарга сорап елый. Наил аны, әйдә, бәрәңге ашыйбыз, дип чормага алып менә. Шунда кәрзин-сандыкта китаплар ята. Ертылган битләрен кайчандыр бәрәңге сылап ябыштырганнар. Балалар шуны куптарып ашыйлар, рәхәт булып китә. Наил акбаш, балтырган, кузгалак, кәҗә сакалы җыеп кайтканда да тамаклары тук кебек тоела кыз туганнарының. Сеңлесе аякларын авыртмасын дип, хастаханәдә ятканда, җиргә коелып калган борчакларны җыеп, болын буйлап кына яланаяк кучтәнәч итеп китергәне дә гомер буена онытылмый.

Өч кыз янында бердәнбер ир-егет булып үскән Наил барысына да таяныч була. Әйтергә кирәк, Сабировлар нәселе, гомумән, авыл халкы өчен зур терәк булган. Сабир бабасы тирә-якта оста мүкләүче буларак дан тоткан. Йорт салган кеше аны ярдәмгә чакырмый калмаган. Әтисе Закир 1936–1937 елларда хуҗалык рәисе булып та эшләгән. Көннәрдән беркөнне ул кулын улының җилкәсенә куя да: «Улым, мин сугышка китәм. Син минем урынга каласың», – дигән сүзләр әйтә. Беренче Бөтендөнья һәм гражданнар сугышын иңләгән әтисе монысыннан да исән-сау кайта. Әмма берничә тапкыр яралана, бик зур авырлыклар күрә. Шуңадыр, күрәсең, кырыслыгы тагын да арта төшә. Ә менә әнисе Нәсимә авылда бер сабыр кеше була. Малай әнисенә охшаган: каударланмый, юкка-барга кызып китми, сүзен дә үлчәп кенә сөйли. Әтнә мәктәбендә авылдан беренчеләрдән булып 10 нчы сыйныфны тәмамлагач, укытучы итеп эшкә җибәрүләре дә шуңа бәйледер әле. Югары белемне барыбер ала ул: Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керә.

Борылыш

Әмма тормыш аңа көтмәгәндә борылышлар әзерли. Егетне район комсомол комитетына эшкә чакыралар. Яшь белгеч еш кына авылларга йөри. Бервакыт шулай бер колхозда рәис кәнәфие бушый. Җитәкчеләре бертуктаусыз алышынып торган бу урынга кемне куярга да аптырыйлар. Шулчак Наилгә күзләре төшә. Баксаң, менә икән бит әзер председатель, эзләп йөрисе дә юк.

Наил аганың күңелендә иң тирән уелып калган вакыт – «Чулпан» колхозында эшләгән еллар. Эшләгән дип әйтү генә җитмәс, мөгаен, аякка бастырган, аның составына кергән авылларны торгызган, алдынгы урынга чыгарып, халыкның ышанычын яулаган еллары. Менә шул ышаныч дигәннәре зур роль уйнаган да инде рәис өчен. Шунысын да әйтергә кирәк: җитәкчеләренең килү-китүеннән миңгерәп беткән Олы Мәңгәр, Иске Мәңгәр, Бәхтияр авыллары халкы 28 яшьлек егет кисәген рәис итеп куюга башта дәррәү каршы төшәләр. Ә 34 ел үткәч, елыйелый озаталар.

Колхоз рәисе бу ышанычны ничек яулый алган да озак еллар буена ничек бу разнадан тайпылмаган? Наил ага белән шул хакта гәпләшәбез.

– Килүгә шуны аңладым: тырышып эшләү, намуслы булу гына җитми, ниндидер яңалык кертергә кирәк иде. Мин килгәндә, колхозчыларга хезмәт хакы түләү юк иде. Беренче чиратта халыкны акчалы итәргә булдым. Мөмкинлекләр әллә ни түгел иде, әлбәттә. Әмма бу бик мөһим адым булды, – диде ул, истәлекләрне барлап.

Шуннан соң рәис колхозчыларның көнкүрешен җиңеләйтү турында уйлана. Терлек асрамый булмый, әмма күкрәк киереп печән чабарлык болыннар бөтенләй юк диярлек. Җаен табып, һәр йортка прессланган печән чүмәләләре тараттыра. Яшьләр туган төбәген ташлап китмәсен өчен, ниләр генә уйлап тапмый ул. Егетләргә әйбәт: урта мәктәп каршында СПТУ филиалы ачыла, алар шунда тракторчы таныклыгы алып чыга. Кызларга да эш таба Наил Закирович: кайчандыр эшләгән артельне яңадан торгыза. Хатын-кызлар тегә, чигә, бәйли башлыйлар, хезмәтенә күрә акча да түләнә. Акрынлап рухи байлыкка да чират җитә. Мәңгәрдә мәдәният йорты салдыра, музыка мәктәбе филиалы ачтыра, баянчылар курсы оештыра. Кичләрен авыл урамнары җыр-моңга, шатлыклы авазларга күмелә. Колхоздагы бөтен торакларны яңабаштан коралар: административ бина, мәдәният йорты, мәктәп җиткерәләр. Кайчандыр латыш балалары, Мәскәүдә татарча укыган балалар ял иткән атаклы пионерлагерь яңадан торгызыла. Анысын да «Чулпан» дип исемлиләр. Наил аганың игелекле эшләреннән тагын берсе була ул. Нәтиҗәсе дә шәп: яшьләр авылда кала башлый. Шулай итеп, ышаныч кабат-кабат яулана.

Райком сүзен тыңлап, өч елга килгән егет бу колхозда утыз елдан артык вакытка «тоткарлана». Теләгәнәирешә. «Чулпан» районда гына түгел, бөтен Татарстанда якты йолдыз булып кабына.

Чаң

Исеме мактап телләргә кергән Наил Сабировны 1985 елда Татарстан Югары Советы халык депутаты итеп сайлыйлар. Гадәттә, булганлыгы йөзенә чыккан кешене беркайда да тик тотмыйлар. Аны да табигатьне һәм тирә-як мохитне саклау комитеты рәисе итеп билгелиләр. «Колхоз рәисләре арасында мин берүзем шундый вазыйфага билгеләндем», – дип горурланып искә ала Наил абый. Горурланырлыгы да бар. Зур эшләр чорына туры килә ул. Кама Аланында атом электр станциясе төзергә тотынганда, нәкъ менә шушы комитет әгъзалары аның Татарстан халкы өчен зур афәт икәнлеген расладылар һәм, тизрәк төзелешне туктатыгыз, дип чаң суктылар. Без һәм киләчәк буыннар аларга зур рәхмәтебезне дә җиткерергә тиешбездер.

Туган җир

– Эштән, бәлки, китмәгән дә булыр идем әле, – ди Наил ага, ул вакытларны искә төшереп. – «Чулпан»ны өч колхозга бүлделәр. Төп сәбәбе шул булды бугай. Дөрес, яшь тә бара иде инде. Аннан районда профсоюз оешмасын җитәкләргә тәкъдим иттеләр. Анда да төп эшем халык мәнфәгатен кайгырту булды.

Менә шул вакытта инде әллә кайчан күңелендә бөреләнгән хыялына бәреп чыгарга ирек бирә Наил ага. Аның туган авылы – Дусымы бар бит әле. Күреп тора: «Игенче» колхозының бер бригадасы булган авыл аерым хуҗалыкка әверелгәч, җитәкчеләр гел алышынып тора, колхоз гел артка тәгәри. Күп кенә авылларның Җир йөзеннән юкка чыга баруы болай да күңелне өшетә. Туган авылы гына андый хәлгә дучар булмасын. Үзенең көче җитмәсә, баһадирдай өч улы бар. Алар ярдәм итәрләр.

Егетләр әтиләре теләген шундук күтәреп алалар. Сабировлар ярдәме белән Дусымда ферма, гараж яңартыла, мәдәният йорты төзекләндерелә, балалар бакчасы, башлангыч мәктәп яңадан төзелеп, медпункт белән бер түбә астына җыйнала. Наил аганың сыйныфташы, язучы Радик Фәизовка музей ачыла. Зират койма белән әйләндереп алына, асфальт юллар түшәлә. Авылда иман авазы да ишетелә башлый. Ил агасын хөрмәтләп, авылдашлары яңа иман йортына «Наил мәчете» дигән исем бирәләр. Наил аганың туган авылына бүген дә юлы өзелми. Чын хуҗа булып, һәр нәрсәне барлап, карап, күз уңында тота ул.

Гаилә

Наилнең комсомол райкомында эшләп йөргән чаклары була. Комыргуҗа авылына килгәч, каршыдан бер чибәр кыз үтеп китә. Егетнең йөрәге урыныннан кузгалгандай була. «Кем булыр икән бу?» Яңа Җөлби авылыннан килгән китапханәче кыз, диләр аңа. Гыйшык уты әнә шулай кабына.

Басулардан кайтып кермәгән рәисне көтеп утыру Ләлә апага да җиңел бирелмәгәндер, әлбәттә.

– Наилне бер күрүдә ошаттым, – ди үзе. 61 ел эчендә авыр сүз әйтешмәдек, ызгышмадык. Бик тәртипле булды ул. Эчмәде, тартмады, колхоз эшеннән дә кайтып кермәде инде. Йорт эшләре өч малай башына төште. Аның каравы дөнья көтәргә өйрәнеп үстеләр. Әтиләре – алар өчен элек кенә түгел, хәзер дә чын үрнәк. Аның киңәшеннән, ризалыгыннан башка бер генә зур эш тә башланмый безнең нәселдә.

Югыйсә егетләр үзләре дә төшеп калганнардан түгел. Һәрберсе үз һөнәренә гашыйк. Бер гаиләдә биш атказанган алар.

Наил ага – РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Ләлә апа – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Рөстәм Сабиров – Татарстанның атказанган нефтьчесе, Илһам Сабиров – Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, төпчекләре Азат Сабиров – Татарстанның атказанган табибы.

Иманым камил: бу исемлек гел арта барыр әле. Бүген Наил ага белән Ләлә апаның 7 оныгы, оныкларының тагын 7 баласы бар. Ә гаиләдәге гореф-гадәтләр шул ук: олыны – олы, кечене кече итә белү, юкка-барга вакланып йөрмәү.

Вакланып йөрмәү дигәннән, Наил ага тормышында да шактый булгандыр ул гаделсезлекләр, Ләлә апага да бик еш сабыр итәргә туры килгәндер. Балаларга да әләкми калмагандыр. Әмма ник берәрсе, шуларны искә алып, күңелен бимазалап утырсын. Монысын да Сабировлар кебек көчле рухлы кешеләр генә булдыра ала шул.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

РӘНИФ ШӘРИПОВ:

«АРТЫК КЫЮ ЯЗГАНЫМНЫ ҮЗЕМ ДӘ БЕЛМИ ИДЕМ»

Шагыйрьнең китабы чыкты. Көттереп. Андый вакытта башта иҗат әһеле өчен дә, укучысы өчен дә сөенеч биләп ала. Аннан соң моңсулык. Киләчәктә татар китабын укучы булырмы? Әдәбият нинди проблемалар кичерә? Татар әдибе абруен төрле конкурслар, грантлар күтәрә аламы? Диңгезче шагыйрь Рәниф ШӘРИПОВ белән әнә шул хакта сөйләштек.

:: «Син язасың, ә мин сакта торам... Барысы да әйбәт булачак!» – дигәнсез бер шигырегездә. Хәзерге вазгыятьтә эчке цензор җиңелсә хәерлерәкме, әллә шагыйрьме?

– Язганда мин уңга-сулга карамадым, чыгарырлармы-юкмы дип уйламадым. Барысы да үз иркендә агылды. «Язганда, язам дип уйлама», – дигән Эрнест Хемингуэй. Уйлый башласаң, ул язылмас та иде. Алга таба әсәрнең язмышы иҗатчыга бәйле түгел.

:: Озак көттереп, «Бөртек-бөртек яктылык» дигән шигырь китабыгыз чыкты. Нибары 600 данә тираж белән... Китапның шулкадәр аз санда басылуын үзегез нидән күрәсез?

– Кәгазь кытлыгыдыр...

:: Бәлки, артык кыю булганга, «Азатлык көне», «Фәүзия» кебек поэмалар да урын алганга шулай аз санда чыккандыр ул?

– «Артык кыю» язганымны үзем дә белми идем әле. Ул бит үзе агыла. Кайвакыт язып өлгереп булмый. Ничек килә, шулай языла да инде. Ләкин, яза башлаганчы, аны әле озак уйлап йөрисең, ул шулай әкренләп өлгерә, җиләк кебек пешә. Ә пешеп җиткәч инде, тизрәк язарга кирәк, юкса бозыла башлый. Андый вакытта уйлап торып буламы соң?

– Аз булса да, берәгәйле! Әйтик, «Зәйтүнә мәхәббәте» поэмасы. Тагын Тукай мәхәббәте турында инде, дип борын җыерыбрак укый башлыйсың да гади җөмләләрдә ил язмышын күреп шаккатасың.

«Ә газраил көн дә җан җыя.
Артта калыр шулай
Айдар да бервакыт,
Һәм югалыр беркөн Фәүзия.
Азатлыкка әйдәп
Мәйдан тота белгән
Батулла да хәлсез тын ала», – дигән юлларны гына алыйк. Безнең киләчәк шулай ук өметсезме, дип сорау да урынсыз шикелле...

– Кайберәүләргә, кайбер вакыйгаларга карасаң, өмет сүнә башлый. Шулай да тормышта, тарихта кайвакыт көтелмәгән, шаккатарлык кискен үзгәрешләр, борылышлар, хәтта могҗизалар килеп чыга...

:: Китапта татар җыры белән саубуллашу да бар. Радио-телевизордан эстрада хәлләрен күзәтеп барасызмы? Татар җыры кайтмаска дип хушлаштымы безнең белән?

– Күзәтәсем дә килми. Кәефне бик тиз төшерәләр. Күпме яздылар, мин дә яздым, ә хәләр начарган-начарга бара. Гасырлардан килгән искиткеч уникаль, кабатланмас татар моңын ничек мыскыл итәләр. Бер популяр җырчыны җенем сөйми иде. Очраклы рәвештә бер татар халык җырын җырлаганын ишеттем дә исем китте – шундый матур итеп җырлый белә икән бит бу ханым. Ә ул сәхнәдән теләсә нәрсә сөйләп, тыңлап булмаслык «шедеврлар» башкарып, популяр җырчыга әйләнгән, үз бәясен генә түгел, халкының бәясен, зәвыгын төшереп йөри. Юлның җиңелрәген сайлаган. Мондый хәлнең сәбәпләре сер түгел.



Автор фотосы

Блиц-сораштыру

– Мөмкинлек булса, тормышыгызда нәрсәне үзгәртер идегез?

– Мәктәпне тәмамлагач, химия-технология институтына түгел, КДУның тарих бүлегенә кергән булыр идем.

– Хәзерге заманны нинди өч сүз белән бәяләп була?

– Гомуми акылдан язу...

– Иң зур теләк?

– Теләкләр күп ул. Барысы да зур.

– Сезнең тормыш китап булса, ул ничек аталыр иде?

– «Бөртек-бөртек яктылык».

:: Язучыга шартлар кирәк, дигәнне еш ишетергә туры килә. «Шартлар» дигәнне сез ничек кабул итәсез?

– Язучы ач булырга тиеш, диючеләр бар. Тыныч, уңайлы шартларда гына иҗат итеп була, ди кайберәүләр. Мин барысын да уздым, төрле шартларда яздым. Барысының да – үз вакыты. Тик шунысы шарт: кечкенәдән балда-майда йөзеп, әсәр язып булмыйдыр ул.

:: Шартлар дигәннән, Тел комиссиясе белән берлектә «Казан утлары» журналы әдәби конкурс үткәрде. Сез анда көч сынап карамадыгыз шикелле. Сәбәбе нидә икән?

– Әдәби конкурслар – иҗат өчен файдасыз ыгы-зыгы дип уйлыйм. Аның өчен мин картайдым инде. Аннан соң, «служенье муз не терпит суеты» диләр бит.

:: Гомумән, әдәби конкурслар белән иҗат кешесенең абруен күтәреп буламы?

– Була, билгеле. Күптән түгел генә Чаллыдан талантлы Лилия Гыйбадуллина бер конкурста бик танылды. Лаеклы рәвештә танылды, абруен тагын да күтәрде.

:: Һәр язучы – аерым бер дөнья, дигәндәй, сезнең иҗатны башка каләм әһелләре күрәләрме, бәялиләрме?

– Язучыларның каләмдәшләрен укымауларын күптән язабыз. Шулай да мине әдәбиятка Сибгат Хәким белән Илдар Юзеев җитәкләп алып керделәр, дип әйтергә була. Килүчеләр дә күп булды, дусларым шактый. Кызганыч, әкренләп китеп бараляр, таянырлык кеше калмый. Ләкин минем иҗатка югары бәя бирүче язучылар аз түгел.

:: Бәяли(ләр) дисәгез, нишләп соң, алайса, төрле премияләргә җиңүчеләр игълан иткәндә, сезнең исем ишетелми? Премияләр өчен фамилиягез туры килмиме әллә?

– Премияләр тирәсендә дә әдәбиятка катнашы булмаган ыгы-зыгы күп. Тәкъдим итеп караучылар булды, алга барып булмады. Сәбәбен ачыклап маташмадым, кирәге дә юк. Күңелем чиста, җаным тыныч.

:: Премияләр турында сүз чыккан икән, Тукай премиясе турында да фикерегезне ишетәсе килә. Быел Флера Гыйззәтуллина үпкәләп-рәнҗеп калды. Бәлки, чынлап та, аны бирү тәртибен үзгәртергә вакыт җиткәндер?

– Әйе, Флера Гыйззәтуллина да бик тәлаек иде. Үзенең легендар баласына 500 мең сум акча таба алмаган бай Татарстанга нинди өмет, нинди ышаныч булсын инде? Аның бирү тәртипләрен бездән сорап торалармы соң?

:: Китапны күпләп чыгаруның файдасы юк, алмыйлар, диләр. Яхшы китап киштәдә ятмый анысы. Сезнең китапка да тузан кунмас шикелле. Сезнең фараз: татар китабын укучы иң соңгы кеше ничәнче елда яшәячәк?

– Татар әдәбиятын, серле татар моңын әле меңнәрчә еллардан соң да галимнәр өйрәнәчәк, дип уйлыйм.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Җыр

«Нинди җыр бу?» – диеп сорамагыз,
Күңел тулы сагыш булганда.
Бик ерактан бер күрергә килгән,
Алар безнең кардәш-туганнар.

Моңланып Ай нурларында кичә,
Син өздереп гармун уйнадың.
Нинди тылсым йөртте, әйтче, туган,
Кытыршы бу тупас кулларың?

Башка килә төрле-төрле уйлар,
Әллә нинди моңлы, зарлы көй.
Хафизәләм-иркәм, ал Зәйнәбем,
Кара урман, Рәйхан, Әллүки.

Бик еракта без яшәдек шулай,
Бер алманы бишкә бүләек.
Кайда гына тир түкмәдек без, әй,
Туган якны сагынып үләек.

Ак калфакның табылган чагы ла,
Туганнарның сагынган чагы.
Саубуллашып, бәхилләшеп калыйк,
Күрешмәбез, ахры, без тагын.

Чәчәкләрне күмгән олы юлның
Без күтәргән кара тузаны.
Син уйнадың кичә. Мин уйладым,
Чит якларда гомер узганын.

Чыңлаган шул гармун телләредәй,
Бер-бер артлы үтте елларым.
Яңрап үткән еллар авазыннан,
Түзмәдем мин, үксеп eладым.

Табылмаган дөнья малы өчен,
Каңгырыйдыр егет башлары.
Ил язмышы безне туган җирдән,
Өмет бирми, алып ташлады.

«Нинди җыр бу?» – диеп сорамагыз,
Күз яшьләре тынны буганда.
Бәхилләшү җыры шушы инде,
Сау булыгыз, кардәш-туганнар.

Идел бит ул, дускай, Идел бит ул,
Ерак бит ул, тирән, киң бит ул.
Татар күргән михнәт дәрьясына,
Күз яшенә аның тиң бит ул.

Әй, мөкатдәс, моңлы тальян гармун,
Уйнадың син бик аз. Нишләдең?
Үксеп-үксеп елый еракларда,
Аерылган кардәш-ишләрең.

Озата барма, дускай, озата барма,
Адаштырмас, бәлки, олы юл.
Без китәбез инде. Сез каласыз.
Татар җыры – матәм җыры ул.

Шәмдәлләрдә генә утлар яна,
Галиябану, Рәйхан, Гөлҗамал,
Мин сагындым сезне... Күзләремнән
Тамчы тама... Сагыш, моң тама...

(«Азатлык көне». Поэмадан өзек)

< Ахыры. Башы 12 август санында

Җәңгиз Йөрүк

КЕШЕЛӘРНЕ ЯЛГЫЗ КАЛДЫРМАГЫЗ



vk.com

Шул көннән бирле Шинаси белән Хаккы ике катлы иске генә агач йортны күзәтәләр. Стамбулдагы башка бик күп йортлардан берние белән дә аерылып тормый ул.

Өй каршыннан гына йомры таш түшәлгән юл уза. Бераз сулдарак ташландык җир. Аларның машинасы шунда тора. Иртә саен алар рапорт язалар.

«Сәгать унда качкынның хатыны Рокыя өйдән чыкты. Базарга барып, әйберләр алды. 11.10да кайтты».

«Даруханәгә барып, йокы даруы алды».

«Өй каршындагы юлда еш кына ике бала уйнап йөри. Өлкәне – Мәхмүт, кечесе Мостафа исемле. Мәхмүт икенче сыйныфта укый. Укытучысының исеме – Мүҗгән. Мәктәптә инде ун ел эшли. Бүген урамнан узып барганда туктап, балаларны сөеп китте, балконда торган әниләре белән сөйләшеп алды. Кечкенә Мостафа артык күп йөгергән, ахры, температурасы күтәрелгән. Кич белән табиб килде, электәге гаилә табибы. Дәрә урамындагы 16 нчы йортта яши...»

«Табиб рәттән өч көн килде. Күршеләре дә күп керә. Исем-фамилияләре, адреслары...»

«Бүген мәктәпкә барганда Мәхмүт туп уйнады. Тубы безнең машинаның астына тәгәрәп кереп киткәч, алып бирдек. Үзе белән таныштык, сагыз белән сыйладык...»

«Бүген урамда бик кызу. Мәхмүт безгә салкын су китерде. Балалар әле безнең кемлекне аңламый. Өйдәгеләр сизенә булса кирәк...»

«Абзыйлары бу йортта бик еш була. Төнге икегә кадәр булмәдә ут яна... Өйгә өч төрле газета килә. Исемнәре...»

«Бүген хатын күршесе белән киного барды. Фильмның исеме...»

«Мәхмүт белән Мостафа безнең янга килеп йөриләр... Әниләре башы авыртып җәфалана... Балалар әтиләрен акча эшләргә киткән, озакламый кайта, дип уйлыйлар. Өйләрендә бер шкаф китап бар, дип сөйләделәр. Нинди китаплар икәнен белмиләр...»

«Гаиләнең тормышында бернинди үзгәреш тә юк, мөгаен, булмас та. Тагын күпме шөгыльләнергә инде бу эш белән?»

Отчетларның исәбе-хисабы юк.

Көз җитте. Мәхмүт мәктәпкә киткәч, Мостафа урамда үзе генә уйный башлады. Урам көннән-көн бушый. Суытты да. Мәхмүт кайткач та, балалар урамга чыкмыйлар инде. Кич булып, караңгы төшкәч кенә, Мәхмүт белән Мостафа машина янына радио тыңларга киләләр. Шымчылар балаларга әтисез ничек кыен икәнен бик яхшы аңлыйлар, аларны көннән-көн ныграк кызганалар, ияләшкәннән-ияләшә баралар иде. Авыр уйларын аралап, үзәкләрен өзеп саркып чыга хисләре. Бу өйнең ялгызлыгымы, сабыйларның яклаучысыз булуымы, яки әниләренә карата ихтыярсыздан туган хөрмәтме, әллә инде барысы да бергәме – балаларны яраттыра. Бу хис ирләрнең күңелендә һаман үсә һәм алар аннан берничек тә котыла алмыйлар иде.

Шинаси белән Хаккы тәмам туйдылар инде. Саран гына яктыртылган өйне, кайчан карама эшкә чумган хатынның яшьле күзләрен, әтиләре фуфайкасыннан сүтеп бәйләнгән яңа свитер киясе көннәрен түземсезләнеп көткән сабыйларны күзәтү ялыктырды.

Нигә бу гаиләнең тормышына болай дорфа, әдәпсез итеп бәреп керделәр соң? Бу күзәтү нәрсәгә кирәк? Аларга үзләренең эшләре өчен – кешеләргә тап төшерә торган гамәлләр эзләү хезмәте өчен оят иде...

Балаларның саф дөньясына кагылырга, өйләрендә ни барын төпченеп сораштырып, мәгълүматларны тикшерү эшендә кулланырга кем хокук биргән аларга? Тынычлыкның бик кадерле икәнен белми бит, әтиләренең качканын да... Аның матур уенчыклар алып кайтасына ышанып көтәләр. Эти кайтыр да, тормышыбыз яңадан рәтләнеп китәр, диләр.

Хәзергә... хатыны тавышсыз гына елый-елый өен, балаларын кайгырта. Ашата-эчертә, юа, ямый, җыештыра. Өйдә искитмәле тәртип. Гөлләргә су сибелгән. Бакчадагы ике лимон агачы яхшылап тәрбияләнгән. Алар янында уйнап йөргән балаларның киемнәре пөхтә, ертыклары ямалган. Ә менә бу ирләргә, балаларның әтисе үз теләгенә каршы килеп, тиеш булганы өчен чит илгә киткәнлектән генә, шушы чисталыктан кер эзләргә туры килә.

Бүтән бер сүз әйтмичә, стаканнарын саклык белән тотып, караңгылыкка кереп югалды. Бераз вакыттан аның гәүдәсе фонарь яктысында күзгә чалынып алды да тагын юкка чыкты. Аннары аның тонык кына яктыртылган парадный ишегеннән кереп китүе күренде.

Мәхмүт киткәч, Хаккы донесение язарга тотынды. Тик эше бер дә алга бармый: бланкка бераз яза да кәгазен йомарлап ташлый, тагын яңадан яза. Икенче бланкны да ертып аткач, гасабиланып:

– Ник бу кадәр җаныбыз әрни соң? – дип куйды. Шунда ук ник әйткәненә үкенде дә үзе: янында утырган Шинаси елмая иде. Хаккы аңа өнәмичә карап алды, ачуы тагын да ныграк кабарды:

– Көлеп утырганчы, тотар да язар идең.

Рим сугышчысы сыман горур килеш китеп югалды бит...

Хәзер чит җирдә тормышыннан канәгать микән ул? Сагынмый микән? Ике лимон агачы, чәчәк атучы гөлләре, тавышсыз елаучы хатыны, йөрәк парәләре турында бер дә уйламый микәнни соң? Балалардан да якынрак тагын ни бар бу дөньяда? Аларны ничек онытырга була? Көрәш шушыларның барысыннан да өстен микәнни?

Мәхмүтнең тавышын ишеткәч, Шинаси айнып киткәндәй булды.

– Мин китим инде, – ди икән малай.

– Ярый, Мәхмүт. Ә бәлки тагын бераз тыңларсың? Бик кызык тапшыру бит.

– Дәресләрен дә хәзерлисе бардыр әле? – дип сорады Хаккы.

– Мәсьәләләр биргәннәр иде. Әни булыша миңа.

– Монда алып чыгасың калган, бергә чишкән булыр идек.

Малай уңайсызланып елмаеп куйды. Бу елмаюда горурлык та, ярату да, әлеге кешеләргә ышану да, чын дуслары булуга шатлану да бар иде. Кечкенәләр дә мондый хискә ия бит! Шушындый мизгелләрнең сафлыгы хәтердә озак еллар сакланачак әле. Бөхетле минутлар кешенең гомер юлын йолдыздай яктыртып торачак.

Мәхмүт, җилдә яргаланып беткән бәләкәй кулларына стаканнарын тотып, машинадан төште.

– Тыныч йокы, – диделәр Хаккы белән Шинаси.

Малай:

– Тыныч йокы, – дип җавап бирде дә,

– Юк инде, бүген синең чират.

– Бу эш мәгънәсез булып тоелмыймы сиңа?

– Тоела да бит, барыбер язарга кирәк инде. Аннан гына беркемгә дә зыян килми ләбаса.

– Зыяны безгә аның, – диде Хаккы.

Шинаси эндәшмәде. Хаккы яңадан язуына тотынды. Хәзер инде рапорт – бер буш шөгыль, язганмы-язган өчен генә эшләнә торган нәрсә. Ләкин барыбер, рапортны үзе язмаган көнне бәхетле көн дип саный ул. Пычрак эш белән шөгыльләнүен онытырга да тырышып карады инде югыйсә, тик хезмәте бурычлы төгәл үтәүне таләп итә шул.

И-и, элек мондый рапортлар язуны чүпкә дә санамый иде ул. Кешеләр язмышына бәйле булгач, башкара торган эшенең эчтәлеге бөтенләй үзгәрде. Башка берәүнең эчке дөньясы, рухи тормышы турында берни белмәгәндә, аны уйлап та карамаганда, никадәр ялгыш фикердә буласың икән! Иң әйбәте – эндәшми тору. Кешенең тәвәккәл, кыю булып кыланууыннан ни файда? Күңеленә салынган бөтен изгелекне читкә тибәргәч, чын кешене ничек тәрбияләп үстерергә соң? Сөепкайгыртып тормасаң, утырткан агачның ботаклары да яшәреп китми бит. Ә адәм баласын мәхәббәтсез ничек үстерергә?

Хаккы, ниһаять, язып бетерде. Аңа һава җитми, күңеле дә урынында түгел иде. Галстугын йолкып алды, күлмәк төймәсен ычкындырып җибәрде.

– Мә укып чык, – дип, кәгазен Шинасига сузды.

Укып чыккач, Шинаси көлемсерәп куйды:

– Белмим шул. Хуҗага ошар микән бу...

– Җиде ай, – диде Хаккы, тавышын күтәреп, – җитте, булды! Ике көн элек үзең дә шулай уйлый идең ич. Безгә бүтән эш бирсеннәр!

Шинаси аны тынычландырырга теләп карады:

– Артык ашыкма әле син. Тагын азрак түзик инде.

– Йа Аллам! Нәрсә син һаман койрык болгыйсың соң? Ике көн элек кенә ни әйткәнеңне оныттың дамыни? Оялыр идең!

– Хаккы, мин ул турыда әйтмәгән идем... – диде Шинаси, телен көчкә әйләндереп. Хаккы, түземсезләнеп, аны бүлдерде:

– Ул турыда, бу турыда дигән булып, авыз эчеңдә ботка пешермә син!

Шинаси җавап бирмәде. Бер-берсен хөрмәт иткән кешеләр арасында килеп чыккан бәхәсләр аларның дуслыгын һич тә бозмый бит ул, киресенчә, ныгыта гына төшә.

Бераздан Хаккы, үпкәләмәдеңме, дигән төсле, дустына күз ташлап алды. Кесәсеннән сигарет пачкасы алып, тартмаучы Шинасига бирде. Тегесе, үзе дә сизмәстән, бер сигарет алды да кабызып җибәрде.

Машина эченә тәмәке төтене тулды. Хаккы тәрәзәне ачты. Урамнан, ургылып, саф һава кергәч, сулыш алулары җиңеләеп китте.

Шинаси тәмәкесен көч-хәлгә яртысына хәтле тартты да төпчеген тәрәзәдән очыртты. Хаккының дәфтәрен алып, нидер язды һәм иптәшенә сузды. Тегесе, укып карагач, канәгать рәвештә:

– Менә хәзер тәртип, – диде.

Рапортны кесәсенә тыкты да уйга калды Хаккы. Бу тормышта тигезлек саклау бигрәк авыр кайчакларда. Берәр бәла килгәндә, дустың ярдәм кулын сузса, бик әйбәт тә. Андый мисаллар азмыни? Чын дуслык яратуга, хөрмәткә нигезләнә бит. Хөрмәт булмаганда, бер-береңә ияләшү дә булмый, булса да, ул кыска гомерле, һава шары кебек – тышы ялтыравык, ә эче буш була. Көч белән генә хөрмәтне, яратуны саклап кала алмыйсың. Ул моңарчы да бала-чага белән аралашкалый иде, ләкин аның йөрәгендә мондый ярату барлыкка килгәне булмады. Бу малайлар белән дуслашкач, Хаккының күңел күзе гүя әлегә хәтле билгеле булмаган бер хакыйкатьне күрә башлады. Бу гади хис кенә түгел, анда акыл да катнашкан иде. Моны белмәгән бәндә аны гаепләячәк, әлбәттә. Башкаларга гаеп ташлау, яңа туган балага исем кушу кебек үк, бик җиңел бит ул.

Аның уйларын Шинаси тавышы бүлдерде:

– Кара әле, Хаккы, балалар әле дә йокларга ятмыйлар, сәгать ун инде югыйсә.

Өйнең тәрәзәсе аша Хаккыга Мәхмүт белән Мостафаның кечкенә шәүләләре күренә иде.

Машинадагы кешеләр өчен бу балалар матурлык билгесе булып тоела. Берни сизми тәрәзә буенда басып торган ике малай ирләргә алар турында кайгыртырга көч бирә, ихтыяҗ тудыра. Билгеле инде, малайлар, тырышып-тырышып, караңгыда машинаны күрергә телиләр. Шинаси алгы фарын кабызып җибәрде. Әйтерсең лә машинадан түгел, аның эчендә утырган кешеләрдән йортка таба яктылык көлтәсе сузылды. Бу яктылык өйнең беренче катында янган ут белән кушылып, икенче кат тәрәзәсендәге балаларга төште. Алар, елмаешып, кул болгадылар.

Яшәүнең, бәхет һәм үлемсезлекнең сере сездә, ярата белүчеләр!

Фәния ФӘИЗОВА тәрҗемәсе

Акчаны ничек сакларга?

Хак лайфхак!

- ✓ Акчаны алган көнне үк туздырмагыз.
- ✓ Хезмәт хакыгызның ким дигәндә 10 процентын җыеп барыгыз.
- ✓ Янчык-кошелёкта акчагызны тәртипләгез, купюралар номиналлары буенча бүленгән булсын.
- ✓ Кибеткә исемлек белән генә йөрегез, исемлектә булмаган, планлаштырылмаган әйбер сатып алынмас.
- ✓ Кибеткә ач килеш бармагыз, ашап барыгыз.
- ✓ Көн саен бухгалтерия алып барырга кирәк: күпме акча эшләдегез һәм күпме туздырдыгыз.
- ✓ Чыгымнарыгызны анализлау өчен аларны «файдалы» һәм «файдасыз»га бүлеп чыгыгыз.
- ✓ Кредит алмаска тырышыгыз, кредит карталарын кулланмагыз.
- ✓ Пассив керем булдырырга тырышыгыз: фатирга кеше кертү, сайт, арендага транспорт бирү һ.б.
- ✓ Сәдака бирергә онытмагыз. Биргән сәдакаларыгыз, һичшиксез, әйләнеп кайтачак.

Әз-мәз мәзәк

Ире төнлә өйгә кайтып керә. Аны кулына таба тоткан хатыны каршы ала.

– Матурым, ят син, йокла, минем тамагым тук.

* * *

Сиңа күптән комплиментлар әйткәннәре юкмы? Казанның Вьетнам базарына барып сайланып, берәр кием киеп кара.

* * *

Мин консерваториядә Штраус буенча диплом якладым. Хәзер авылда страус асрыйм.

* * *

– Исемең ничек?
– Олег.
– Тулы исемең?
– Олегатор.

* * *

– Кая киттең?
– Базарга.
– Нәрсә аласың?
– Әйбер алырга акчам юк, сатучыларны котыртып кайтам.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Яго, хәмер, арт, Әлмира, Сират, Атабай, дәү, йомгак, Люстра, Ира, Мәк, ызан, Рәсимә, Ефәк, Омута, рәт, Ми, Воронеж, ТТ, Паль, багучы, анар, ләм, крем, Мини, Гайсә, Сәнифә, агай, Нил, Анискин, пан, Әлшәй.

Вертикаль: сәлкеш, Гата, Рөстәм, Кипурс, тары, ач, Әхтәм, азатлык, Анапа, Регина, Имаметдинов, Алинә, Мокамай, ярар, Амур, Акыш, Рамай, торак, оят, йомран, Сорнай, мә, Жулин, Дамир, Әни, Әкәмәт, миф, кәттә.

Беләсең килсә

1 **Күпләр моны белми, әмма әлеге милләттәшебез кайчандыр энергетика техникумын тәмамлаган:**
а) Камил Кәримов;
б) Камил Сәмигуллин;
в) Камил Ларин.

2 **1997 елда чыккан «Титаник» фильмының режиссеры кем?**
а) Кэмерон Диас;
б) Джеймс Кэмерон;
в) Джеймс Бонд.

3 **Төзүчеләр телендә бу сүз «аска төшер» дигәнне аңлата:**
а) «майна»;
б) «майла»;
в) «байда».

4 **Фәннең «ономастика» дигән өлкәсе нәрсәне өйрәнә?**
а) ялгызлык исемнәрне;
б) омонимнарны;
в) антонимнарны.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. а); 4. а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 16052 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 320

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.)**.

16+